Гамирҗан Дәүләтшин

БОРЫН-БОРЫН ЗАМАНДА...

# МИФ ДИН СӘНГАТЬ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 94(3) : 373.3/5
ББК 63.3(0)3
Д94

**Дәүләтшин, Г.М.**

Д94 Борын-борын заманда... : Миф, дин, сәнгать / Гамирҗан Дәүләтшин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 51 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-01855-5

Китапта беренче кешелек җәмгыяте чорындагы рухи тормыш: миф, дин, сәнгать турында бәян ителә. Татар халкының традицион культурасына караган күп кенә күренешләрнең тамырлары ачыла.

Ул гомуми белем бирү мәктәпләренең урта һәм югары сыйныф укучыларына тәкъдим ителә. Китаптан шулай ук студентлар, укытучылар, гомумән, халкыбыз тарихы белән кызыксынучы барлык укучылар да файдалана ала.

ÓÄÊ 94(3) : 373.3/5
ÁÁÊ 63.3(0)3

ISBN 978-5-298-01855-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Дәүләтшин Г.М., 2009

## КЕРЕШ

Кешелекнең иң борынгы чоры кеше барлыкка килгән вакыттан сыйнфый җәмгыятьләр оешканга кадәрге дәверне үз эченә ала. Беренче кешеләр моннан 2–2,5 миллион еллар элек табигатьтән, хайваннар дөньясыннан аерылып чыккан. Яңа ачыш-табышлар әлеге санның тагын да зуррак булуын күрсәтә. Бу – гаять зур вакыт, чөнки сүз минутлар, сәгатьләр, көннәр, айлар турында түгел, еллар турында бара. Әйдәгез, моны аңлар өчен, 100 елны бер сәгать итеп карыйк. Болай уйлаганда, Европа кешесенең тарихы тулаем 208 көнгә тигез булыр иде. Шуның 204 көне – беренче кешелек җәмгыятенә, калган 4 көне генә дәүләтләр, сыйныфлар, язу барлыкка килеп, безнең көннәргә кадәр җиткән вакытка туры килә. Шулай итеп, бөтен кешелек тарихының 98% тан артыгы борынгы заманга – беренче кешелек җәмгыяте чорына карый.

Бу дәвернең рухи тормышы күп галимнәр тарафыннан өйрәнелгән. Шуңа да карамастан әлеге чорга һәм бигрәк тә ул вакытта яшәгән кешеләрнең рухи дөньясын өйрәнүгә моңа кадәр җитәрлек игътибар бирелмәде. Төрки халыкларның борынгы бабалары тарихын өйрәнү яссылыгында караганда да бу шулай. Татар кешесе беренче питекантроп (грек телендә pithekos – «маймыл», anthropos – «кеше» мәгънәсен аңлата) булмаса да, беренче кешелек җәмгыятенең рухи тормышын ачыклау безнең халкыбыз өчен дә әһәмиятле.

Дөрес, борынгы чорда кешеләр Җир шарының теләсә кайсы урынында бер үк юлны үткән, аның гомуми проблемалары фәндә шактый өйрәнелгән. Безнең якларда да иң борынгы чорның үзенчәлекләре сакланган. Бу төрки дөньяның иң борынгы тамырларына да карый һәм аларны әһәмиятсез дип әйтү дөрес түгел. Киләчәктә шушы вак-төяк булып күренгән сыйфатлардан милли культуралары, диннәре, телләре һ.б. үзенчәлекләре белән аерылып торган кабиләләр, халыклар барлыкка килгән дә инде.

Беренче кешелек җәмгыяте культурасын белмичә, урта гасырлар культурасын гына түгел, хәзерге халыкларның, шул исәптән татар халкының да милли-мәдәни үсешен билгеләү мөмкин түгел. Халкыбыз һәм аның бабалары яшәгән Идел, Чулман, Урал, Агыйдел буйларын, Себер киңлекләрен генә алсак та, биредә беренче кешелек җәмгыятеннән калган ядкәрләр күпләп табыла.

Әлбәттә, борынгы кешеләрнең рухи дөньясына үтеп керү бик авыр эш, чөнки борынгы дәвер язма чыганакларда теркәлеп калмаган. Алда әйтелгәнчә, язу әле бик соң, моннан биш мең ел чамасы элек, беренче кешелек җәмгыяте таркалгач кына барлыкка килә. Ул чор тулысын-


ча өйрәнелмәгәнгә, беренче кешелек җәмгыяте кешеләрен үтә кыргый итеп бәяләү таралган. Археологик истәлекләр дә бик аз калган: таш кораллар, хайван сөякләре һ.б. Шулай да җир йөзендә кайбер кабиләләр соңгы гасырларга кадәр беренчел халәттә яшәгәннәр, һәм сирәк булса да алар бүген дә очрый. Ул кабиләләрнең рухи дөньясына караган иң әһәмиятле күренешләр меңәр еллар аша бүгенге көннәргә кадәр үзгәрешсез диярлек килеп җиткән. Борынгы халыклар белән әле күптән түгел генә беренче кешелек җәмгыятендә яшәгән Көньяк Америка индеецларының, Австралия, Африканың кайбер төбәкләрендә яшәүче халыкларның да төп карашлары арасында охшашлыклар аз түгел. Гомумән, беренче кешеләрнең рухи дөньясы Җир шарының теләсә нинди ноктасында да, нигездә, аерылмый. Шуңа күрә аларның рухи тормышын чагыштырулар, логик фикерләүләр аша өйрәнү кешелек дөньясындагы иң күренекле һәм әһәмиятле гореф-гадәтләрне, йолаларны, карашларны башка халыкларга да бәйле рәвештә торгызырга мөмкинлек бирә.

Йөз меңнәрчә еллар үтеп, әлеге мирас безнең көннәргә кадәр ничек килеп җиткән, буыннан буынга ничек тапшырылган соң? Бу бары тик кешеләрнең аралашулары, күмәк йола-эшләрдә турыдан-туры катнашулары нәтиҗәсендә генә мөмкин булган.

Борынгы кешеләр, тормыш, яшәү шартлары бик авыр булу сәбәпле, бик аз, уртача 25–35 ел гына яшәгән. Хәзерге заман кешесе бу яшьләрдә мөстәкыйль тормышка яңа аяк баса әле. Бу вакыт эчендә борынгы кеше үзенә тапшырылган тәҗрибәне үзләштерергә һәм киләчәк буынга тапшырырга гына өлгергән. Еш кына ул үзе дә, тиешенчә тәҗрибә тупларга өлгермичә һәм аны балаларына мирас итеп калдыра алмыйча, фани дөньядан китеп барган. Шунлыктан киләчәк буын да башлыча элгәрләренең казанышларын гына кабатларга мәҗбүр булган. Геометриягә күчергәндә, бу үсеш спираль буенча түгел, бәлки әйләнә рәвешендә генә барган. Бер тамчы суга охшаш көннәр, атналар, айлар, еллар... йөз меңнәрчә еллар үткән. Шуңа күрә борынгы кешелек җәмгыяте бик озакка сузылган.

Шулай да борынгы кеше мирасны киләчәк буыннарга тапшыру

*Кешелекнең биологик үсеше*






Соңгы таш гасыры «мамонт аулаучылар» авылы

өчен иң уңышлы һәм үтемле юлларны таба алган. Аның беренче юлы – мавыктыргыч хикәяләү чаралары: мифлар, риваятьләр, легендалар. Искиткеч кызык, серле сюжетлы бу хикәяләр бер сөйләүдә кеше, аеруча балалар аңында сеңеп калганнар, аның өчен гомер буе сабак, рухландыргыч чара булганнар. Мирасны тапшыруның икенче юлы – бөтен ыру катнашында уздырылган күмәк йола бәйрәмнәре, гореф-гадәтләр.

Беренче кешелек җәмгыяте турында без зур хөрмәт белән сөйләргә, аны зур хәрефтән язарга тиешбез. Бу – кешелеккә хас булган һәм аңа



һәрчак юлдаш булачак иң әһәмиятле күренешләрнең, чараларның барлыкка килгән вакыты. Бар да беренче: эш һәм сугыш кораллары да, кием-салым һәм учак та, арбалар һәм көймәләр дә, йортлар да, җырлар һәм әкиятләр дә, табышмаклар һәм әйтемнәр дә, бию һәм театр да, рәсемнәр һәм сыннар да. Шушы беренче адымнар ясалмаса, бүгенге көннең космик ракеталары да, компьютерлары да булмас иде.

Кешелекнең бала чагында кеше үзе дә сабый бала кебек булган. Ул үзен әйләнә-тирә дөньяның аерылгысыз бер кисәге итеп тойган. «Мин»не «мин түгел»дән аера белмәгән. Табигать белән турыдан-туры аралашып яшәгән. Табигатьтәге үзгәрешләр тормыш шартларының да кискен алышынуына китергән. Азык-төлек чыганагы булган хайваннарның гадәти яшәгән җирләреннән күчеп китүе кешеләрне ризыктан мәхрүм иткән, каты салкыннар һәм эсселек, корылык һәм су басу кебек афәтләр экологик катастрофалар китереп чыгарган. Борынгы кеше мондый стрессларга каршы тора алмаган. Бу хәлләр үз чиратында күп кенә ыру һәм кабиләләрнең юкка чыгуына китергән. Кеше үзенең көчсезлеген тагын да ачыграк тойган. Шулай да ул нинди юллар белән булса да афәтләргә каршы торырга һәм табигатькә тәэсир итәргә омтылган. Бу чаралар исә шул чордагы кешенең аңы, тәҗрибәсе, мөмкинлекләреннән чыгып сайланган. Әйтик: аерым йолалар, магик эндәшләр, хәрәкәтләр һ.б.

Үзен әйләндереп алган дөньяны борынгы кеше җанлы итеп кабул иткән. Кыздырып торучы кояш та, салкын ай да, тын гына агучы елгалар да, шарлавыклар да, кара урман, андагы аю, болан да кеше кебек көлә, елый, сөйләшә, кайгыра белә дип уйлаган ул. Без барыбыз да – кешеләрнең кош-кортларга, хайваннарга, соңгыларының кешеләргә әверелүләре хакындагы әкиятләрне укып үскән кешеләр. Борынгы кеше исә моңа чын күңелдән ышанган. Бу аның аңында үзен әйләндереп алган әйбер, күренешләр хакында тотрыклы төшенчәләрнең булмавы белән аңлатыла. Мондый тотрыксызлык бер әйбер яисә күренешнең икенчесенә әверелү мөмкинлегенә ышану китереп чыгарган. Әверелешләр туктаусыз барган. Кеше белән табигать арасында киртә булмау фикере кеше аңына сеңгән. Кеше – табигать мохитенә, ә табигать кеше карамагына күчә алган.

## МИФ

«Миф» диюгә, мөгаен, укучыларның күбесе мәктәп дәреслекләре аша таныш Борынгы Греция мифларын искә төшерер. Антик мифларның шул дәрәҗәдә билгеле булуында аларны үзләренең әсәрләрендә баеткан, тирәнәйткән һәм матурлаган Борынгы Греция язучыларының, шагыйрь һәм философларының өлеше зур. Алар арасында Гомерның «Илиада» һәм «Одиссея», Эсхилның «Прометей», Еврипидның (Эврипид) «Геракл» әсәрләре аеруча күренеклеләрдән санала. Мифологик хикәяләү ул дәвердә язучының үз идея һәм сюжетларын бирү өчен гадәти әдәби калыпка әверелгән.

Мифлар бары антик чор өчен генә хас күренеш түгел. Борынгылыкта Җир шарындагы һәр халык үзенә генә хас мифологик системага ия булган. Ул борынгы кешенең киеренке фикер сөреше, бу бербөтен әйләнә-тирә кайчан, нәрсә өчен һәм ничек барлыкка килгән, ул нинди кануннарга буйсына һәм аның үзенә нинди таләпләр куела кебек иң мөһим сорауларга җавап бирергә омтылыш нәтиҗәсендә туган. Танып белү мөмкинлекләре әле бик чикле булганга, борынгылар, табигать күренешләренә хыялларында җан өреп, яңа, фантастик чынбарлык тудырганнар. Бабаларыбыз дөньяны үзләренә якын вакыйгалар һәм ыру-кабилә мөнәсәбәтләре күзлеге аша үзләштергәннәр. Аларның дөньяны танып белүләре нечкә күзәтүчәнлеккә, стихияле материализмга һәм беркатлы диалектикага нигезләнгән булган. Шунысы ачык билгеле: бу үзенчәлекле танып белү кешелек үсешендә зарури баскыч булган, ансыз алга китеп булмаган. Синтетик, бүлгәләнмәгән берлектә мифология үз эченә фән, фәлсәфә, сәясәт, сәнгать башлангычларын алган. Мифларны тудырган фантазия, хыял әле чын мәгънәсендә сәнгатьчә фикерләү булмаса да, аңа уңдырышлы җирлек әзерләгән. Юкка гына бөек шагыйребез Габдулла Тукай аларны «шагыйранә ялган» дип атамаган.

Мифлар борынгы кеше тормышының бар ягын да үз эченә алган. Ул вакыт өчен алар иҗтимагый фикернең бердәнбер һәм универсаль шәкеле булып хезмәт иткән. Шулай итеп миф борынгы кешегә бер үк вакытта сәнгать тә, белем, тарих, астрономия, география, педагогика чыганагы да булган. Киләчәк мәдәниятнең яралгылары да мифларда барлыкка килгән. Миф, грекчадан тәрҗемә иткәндә, «сүз», «хикәят» мәгънәләрен аңлатса да, ул сынлы сәнгать, җыр, биюләр аша да сурәтләнә алган. Борынгы кеше мифларга ышанган. Әмма, диннән аермалы буларак, аларга табынмаган. Мифлар, дингә, әкияткә якын булса да, асылда беренчел җәмгыятьнең чынбарлыгын чагылдырган. Антик чорның бөек фикер иясе Аристотель юкка гына аларны «дөрес-

лекне хәбәр итүче ялган хикәятләр» дип атамаган. Мифларда дөньяның килеп чыгышы, төзелеше, беренче кешенең, ыруның, аерым җисем һәм күренешләрнең барлыкка килүе хакында бәян ителгән. Аерым җисем һәм күренешне барлыкка китерүче шәхесләрне мифологиядә «культура геройлары» дип йөртәләр, чөнки алар кешеләрне беренче тапкыр ут алдырырга, көймәләр һ.б. әйберләр ясарга өйрәткәннәр. Шундыйлардан грек мифологиясендә Прометей образы аеруча күренекле. Алар гадәттә беренчел бабалар, демиурглар булганнар. Беренчел көнкүрешнең хикәяләү фольклорында һәм мифларында үзәк персонажлар булып торганнар.

Мифлар, югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, этиологик, космогоник, астраль, тотемистик һ.б. төрләргә бүленә.



*Кешеләргә ут өләшкән өчен Зевс тарафыннан мәңгелек җәзага тартылган Прометей*

**Этиологик мифлар** – төрле табигый, мәдәни үзенчәлекләрнең, иҗтимагый күренешләрнең барлыкка килү сәбәпләрен аңлата торган мифлар. Әлеге төркемгә күпчелек мифлар карый. Мәсәлән, татар халкының «Чыршы ни өчен мәңге яшел?» легендасында болай хикәяләнә: «Болгар патшасы, бик картайгач, үзенең бер батырын мәңгелек суы алып кайту өчен Боз диңгезенә җибәрә. Батыр, бик күп урман-сулар үтеп, таулар-ташлар аша Боз диңгезе буена барып җитә. Диңгез эчендә бер утрау бар икән. Утрауда мәңгелек суы чишмә булып бәреп чыга, ди. Батыр, шул чишмәгә хәтле барып, аннан күн капчыгына мәңгелек суы тутыра да кайту юлына борыла. Урманнар аша кайта торгач, ямьле Ашыт суы буйларына җитә. Бу җирләрдә кап-кара чыршы-нарат урманнары үсеп утыра икән. Батыр, озын юллар үтеп арыгач, Ашыт буйларында ял итәргә була. Бер яшь кенә чыршы төбенә ятып йоклый. Йоклаганда, сулы капчыгын аяк очына куйган була. Шунда, төшләнеп, аягы белән капчыгын тибеп аудара. Аның суы тирә-якта үскән чыршы-нарат төпләренә түгелә. Шул судан чыршы-нарат агачлары мәңге яшел булып калганнар, ди. Батыр, патша янына кайтмыйча, Ашыт буйларында яшәп калган».

Җисемнәрнең барлыкка килүендә аерым персонажлар зур роль уйный. Аларны «культура геройлары» дип йөртәләр, дидек. Шундыйлардан иң күренеклесе – кешеләргә ут бирүче Прометей. Ул, Гефест һәм Афина остаханәсеннән ут урлап, аны кешеләргә бүләк итә, кешелекне техник прогресска китерә. Чын кешелек утсыз яши алмый. Ут ул – җылылык, яктылык чыганагы. Моннан тыш Прометей кешеләрне йортлар, кораблар төзергә, кием кияргә, укырга-язарга, санарга, ел фасылларын аерырга өйрәтә. Моның өчен Зевс аны җәзага тарта: Скифиядәге Кавказ тау кыясына тимер чылбырлар белән беркетә. Аның бавырын һәр көнне бөркет килеп чукый. Бавыр тагын элекке хәленә килә. Бөркет тагын килеп чукый. Шулай итеп, кешеләргә иң кирәк нәрсәләрне, беренче чиратта утны биргән Прометей мәңгелек

коточкыч җәзага дучар ителә. Әмма кешеләр хакына Прометей барысына да түзә.

**Космогоник мифлар** дөньяның барлыкка килүе, төзелеше хакында сөйли. Борынгы кеше үзен әйләнә-тирәнең генә түгел, бөтен галәмнең, космосның аерылгысыз бер бөртеге итеп тойган.

Кешеләрне борынгы заманнарда ук «Боларның барысы кайдан һәм нәрсәдән барлыкка килгән?» дигән сорау борчыган.

Әүвәл башлап ни бөтте  
(ягъни: яралды, барлыкка килде)?  
Ай бөтте дә, көн бөтте.  
Икенчеләй ни бөтте?  
Күк бөтте дә, җир бөтте...



*Фантастик кош сурәте төшерелгән чигә алкасы. Алтыннан эшләнгән. XI–XII гасырлар*

Бу мәңгелек сорау борынгы татар халык шигырендә шушы рәвешле куела һәм хәл ителә: әүвәл Ай белән Кояш ярала, аннары Күк белән Җир барлыкка килә.

Икенче бер борынгы һәм күп кенә халыкларда таралган караш буенча дөнья барлыкка килү турындагы космогоник карашлар болгар чигә алкаларында чагылыш тапкан. Алар – болгар ювелир сәнгатенең җәүһәрләре.

Алтын алкага бизәкләп эшләнгән йомырка яки имән чикләвеге сыман өч алтын төймә беркетелгән. Бу өч төймә алканың нәфис чылбырларына да асылган. Алкага томшыгына алтын бөртек капкан фантастик кош сыны коелган. Әлеге сынлы сәнгать сюжеты нәрсә хакында сөйли? Беренчел океанда йөзеп йөргән фантастик кош йомыркаларыннан дөньяның төп җисемнәре яралган. Борынгы бабаларыбыз фикеренчә, кошның өч йомыркасыннан Җир, Кояш, Ай (өч төймә) барлыкка килгән. Ә томшыгына бөртек капкан фантастик кош нәрсәне аңлата? Башта дөнья судан гына торган. Фантастик кош, дөньяның бертөрлелегеннән туеп, көннәрдән бер көнне океан төбеннән бер кабым балчык алып чыккан. Шуннан коры җир, Җир шары барлыкка килгән. «Үзә көк тәңри, асра йагыз йир кылындукта, әкин ара кеши оглы кылынмуш» (ягъни: өстә – зәңгәр күк, аста көрән җир барлыкка килгәч, ике арада кеше яралды). Борынгы төркиләрнең Күлтәгин һәм Мәгыйлән хан хөрмәтенә куелган зур каберташ язмасы шушы сүзләр белән башланып китә.



*Дөнья барлыкка килү. Рушан Шәмсетдинов рәсеме*

Борынгы төркиләр дөнья ярatылышын болай күз алдына китергәннәр: башта Күк белән Җир бергә кушылып, буталып, хаос тәшкил иткәннәр. Билгеле бер вакыттан соң Күк белән Җир бер-берсеннән аерылган: өстә – чиста Күк, аста әле хаостан бик нык аерылып җитмәгән җирән Җир барлыкка килгән. Кеше бер үк вакытта Күк улы да, Җир улы да булып калган. Ул хаостан Күк белән Җирне аеручы һәм Җир-

гә басып Күк гөмбәзен тотып торучы – борынгы грек мифологиясендәге Атлант буларак та күз алдына килә. Табигать стихияләре яки иҗтимагый афәтләр (гражданнар сугышы, тышкы дошманнар белән сугышлар) вакытында Күк белән Җир беренчел халәтләренә – хаоска якынаерга мөмкиннәр. Без хәзер дә ыгы-зыгы, сугыш-фәлән булса, «күк белән җир тоташкан кебек булды» дип әйтәбез.

Борынгы бабаларыбыз фикеренчә, дөньяның төп ике үлчәме булган: вертикаль һәм горизонталь дөньялар. Вертикаль дөнья өч өлештән торган:

1) югары дөнья – Күк, Тәңре дөньясы;
2) урта дөнья – Җир өсте. Ул «Удук Йир-Суб» – Изге Җир-Су алласы белән идарә ителә;
3) җир асты – үлеләр дөньясы. Аның белән Өрклиг исемле алла идарә итә.



*Җир асты дөньясы алласы Өрклиг*

Бу дөньялар арасында күченеп йөреп була. Күчену чарасы булып изге биек таулар, биек ялгыз агачлар, кошлар, канатлы атлар хезмәт итә. Алар – Юл тәңресе карамагында. Юл тәңреләре алмачуар атларда Күк, Тәңре теләген «җиренә җиткерәләр». Чиста җан шулар ярдәмендә күккә аша. Төркиләрнең күренекле кешеләре каберләре өстендә корылган мемориаль комплекслар да космик төзелешне, җиһан моделен хәтерләтә. Алар Күк һәм Җир символлары – бер-берсенә камалган турыпочмаклык (Җир, җир өсте) һәм түгәрәктән (Күк һәм күк гөмбәзе) гыйбарәт. Үзәк Азия күчмә кабиләләре – һуннар һәм төркиләр фикеренчә, Җирнең дүрт ягы диңгезләр белән юылган квадратны тәшкил итә.

**Астраль мифлар** – күк җисемнәре турындагы мифлар.

Күк йөзе, ничек күренсә, шулай кабул ителгән. Борынгы кешегә реаль белем җитмәсә, аңа хыял, мифлар ярдәмгә килгән. Бик борынгы заманнардан алып күк җисемнәренең төгәл терминологиясе булдырылган. Хәзер дә күп кенә төрки телләрдә күк җисемнәренең исемнәре охшаш. Бу тәңгәллекнең сәбәбен борынгы төрки уртаклык чорыннан эзләргә кирәк. Шуларның кайберләрен карап узыйк.

*Тимер казык (Котып йолдызы).* Борынгылар аны күкнең үзәге буларак кабул иткән. Каккан казык кебек һаман бер урында торганга, аңа шундый исем бирелгән. Даими урыны булганга күрә, ул күктә дә, җирдә дә төп ышанычлы ориентир булган. «Айга карап адашсаң, атыңны Тимер казыкка бәйлә» диелә халык мәкалендә. Тимер казыкның бер урында гына торуы аның янындагы башка йолдызларның да исемнәрен китереп чыгарган. Мәсәлән, Җидегән йолдызга таба ике йолдыз Акбүзат һәм Күкбүзат дип аталган. Алар халык хыялында Тимер казыкка бәйләп куелган атлар булганнар, үлән ашый-ашый, туктаусыз Тимер казык тирәсендә әйләнгәннәр.

*Җидегән йолдыз.* Сан белән ясалган йолдыз исемнәре бирәү генә

түгел: «биш йолдыз», «алты йолдыз», «унике йолдыз». Шулай итеп, күк йөзе арифметик гамәлләр өчен дә, санау тәҗрибәсе өчен дә җирлек булган. Гомумән, йолдызларны санау үзе үк саваплы эш булып саналган. «Җидегән йолдыз җиде, имеш; җиде санасаң – савап, имеш» диелә мәкальдә. Бу йолдыз (йолдызлык) Тимер казык янында сәгать угы кебек әйләнгән һәм шуңа карап вакытны да чамалап булган. Аның икенче исеме дә бар – Чүмеч яки Тустаган йолдыз.

*Өлкәр (Өркәр) йолдыз.* Бу – бик борынгы исем. Татар халык мәкальләрендә бу йолдыз (йолдызлык) засадада торучы алты сугышчы егет рәвешендә сурәтләнә.

*Көянтә йолдыз (Орион).* «Биш кыз бер көянтә күтәргәннәр, төн буена су ташыйлар». Менә ни рәвешле шагыйранә кабул иткән бу йолдызны бабаларыбыз.

Матур исемле тагын бик күп йолдызлар бар әле. *Чулпан йолдыз* (*Венера*), *Зөһрә йолдыз (Вега)* һ.б.

Менә бу шигырьне күк йөзенең кечкенә картасы дип кабул итәргә мөмкин:

Җидегән җиде кыз,
Ай янында Чулпан кыз,
Унике йолдыз – унике кыз,
Тимер казык беръялгыз.

Ә бу мәкальдә зур фәлсәфә ята: «Кояш нурга бай, ай моңга бай, йолдыз уйга бай». Борынгы бабаларыбызга җәйге аяз кара төннәрдә иксез-чиксез далада Күк дөньясы белән бергә-бер калырга туры килгән. Алар, аның белән кушылгандай булып, уйга калганнар. Аңа сокланганнар, аны өйрәнгәннәр. Күк дөньясын үзләренә яхшы таныш предметлар, күренешләр аша бәяләгәннәр. Мифларны, үзләренең хыялларын эшкә җиккәннәр.


*Болгар чүлмәкләрендә кояш сурәте*



Болгар сәнгать әсәрләрендә, гомумән, көнкүреш әйберләрендә, кояш һәм аның символларын аңлаткан бизәкләр еш очрый.

Бу хәл кояш образының бабаларыбыз мифологиясендә үзәк урынны тотуы һәм аңа бәйләнешле космогоник карашларның киң таралуы хакында сөйли. Күк җисемнәре, кеше кыяфәтендә (Сукояр, Игезәкләр, Укчы һ.б. йолдызлыклар) күзаллангančы, элгәрәк кошлар һәм канатлы хайваннар рәвешендә кабул ителгәннәр. Кояшны еш кына канатлы җан иясе белән тәңгәлләштергәннәр. Күктә булгач, анда ничек канатсыз тора алсын инде! Канатлы кояш рәсемнәре, сыннар болгар алкаларында, чүлмәк тышларында очрый. Кояшның күк гөмбәзе буенча хәрәкәте кош, канатлы ат һ.б.ларның очышы буларак кабул ителгән.

*Канатлы кояш рәсемнәре төшерелгән борынгы болгар бизәнү әйберләре. Керамика*



Борынгы кеше айдагы тапларның барлыкка килүен дә үзенчә аңлаткан. Айга күтәрелгән Зөһрә кыз турында безнең ишеткәнебез, укыганыбыз бар

инде. Ир белән хатынның бик матур, бик уңган Зөһрә исемле бердәнбер кызлары булган. Әнисе үлеп киткәч, әтисе башка хатынга өйләнгән. Кызның үги анасы бик усал булган. Барлык авыр эшләрне кыздан эшләткән. Шулай бервакыт, эш булмагач, үги ана Зөһрәгә, иләк белән су ташып, төпсез кисмәкне тутырырга кушкан. Су ташый-ташый, кыз бик арыган. Ә кисмәк тулмый да тулмый икән. Кызның түзәр хәле калмаган. Менә айлы төн дә җиткән. Кыз, җирдә болай интеккәнче дип, Айга үзен алуны сорап ялварган. Зөһрә айга ашкан. Ул хәзер дә шунда, ди. Әтисен сагынуын басалмыйча, көянтәсен асып, гел җиргә карап тора икән...

**Тотемистик мифлар** ыруның килеп чыгышы һәм аның башлангычы – хайван баба хакында мәгълүмат бирә. Алар диннең иң борынгы формасы булган тотемизмның аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр. Төп фикер шуннан гыйбарәт: ыруның хайван бабадан башлануы ыру кешеләренең тотем хайван белән туганлыгын билгели. Без алар хакында алга таба иң борынгы дин булган тотемизм белән бәйле рәвештә танышырбыз. Мифологик сюжетларда күбрәк тотем бабаның маҗаралары, гамәлләре хакында сүз бара. Борынгы төрки чорларда ук таралган һәм Кытай чыганакларында теркәлеп калган, тотем бабалар белән бәйләнешле бер генеалогик риваятьтә Һунну (Сөн) йортыннан булган Ашина ыруының Көнбатыш диңгезе (Каспий, Азов) буенда дошманнары тарафыннан кырылып бетүләре хакында сүз бара. Бу сугышта


*Ашина ыруының килеп чыгышы турындагы борынгы төрки генеалогик легендага иллюстрация. Заһир Хәкимов рәсеме*



ун яшьлек бер малай гына исән кала. Аны да дошманнары табып алалар да, кул-аягын чабып өзеп, сазлыкка ташлыйлар. Үлемгә дучар ителгән малайны ана бүре тәрбияләп үстерә. Ун елдан соң бу егет дошманнары белән сугышта үтерелә. Ана бүре исә таулар белән әйләндереп алынган далага кереп яшеренә һәм шунда ун ир бала тудыра. Өлкәненә Ашина («бөек, затлы бүре» дигән мәгънәне белдерә) исемен бирә.

Риваятьнең уйгырларның килеп чыгышы белән бәйле башка вариантлары малай урынында кыз бала, ана бүре урынында ата бүре булуы хакында сөйли. Таулар белән әйләндереп алынган дала башка сүз белән – «мәгарә» дип тә йөртелә. Кытай чыганакларында бу мәгарә болай тасвирлана: «Тауларда мәгарә бар. Ә мәгарәдә куе үлән белән капланган берничә ли (кытай озынлык үлчәү берәмлеге) тигезлек бар». Төркиләрнең легендар шәҗәрәсенә һәм аның башында торучы Угыз (Үгез) ханга багышланган «Угызнамә» дастанында да (борынгы уйгыр кульъязмасында теркәлеп калган) Күк Бүре (Небесный Волк) төркиләрнең данлы җиңүләрендә әһәмиятле роль уйный – алдан юл күрсәтеп бара.

Гасырлар аша үтеп һәм билгеле бер үзгәрешләр кичереп, бу тотемистик легенда болгарларда да дәвам итә. Моны монгол яуларына кадәр үк Болгар илендә таралган «гарипләр» исеме белән билгеле җиз сыннар раслый. Борынгы төрки кабиләләр яшәгән төбәкләрдә табылган мондый сыннар барс яисә бүрегә атланып утырган гарип ир-ат яки хатын-кызны сурәтли. Болгар җирендә табылган һәм борынгы генеалогик риваятьне чагылдырган сыннарда гомумтөрки тотем бүре болгар тотемы барска алыштырыла. Бу хәл аерым кабиләләрнең, шул исәптән болгарларның, гомумтөрки дөньядан аерылып чыга башлаулары белән бәйле. Гомумтөрки тотем да үзгәрә. Әлеге сыннар арасында Маклашеевка авылы янында табылган (хәзерге Спас районы) сын аеруча игътибарга лаек. Мөгезле барс формасында коелган йозак өстенә хатын-кыз атланган. Аның уң ягы гарипләнгән: күзе чыккан, аягы, кулы чабылган. Сул кулы белән ул баласын күкрәгенә кыскан. Йозак-сыннар бар да югарыда китерелгән мифологик легенданы хәтерләтә. Шунысы игътибарга лаек: сыннарда кеше баба гарип итеп сурәтләнә. Борынгылар бабалар рухын сукыр, гарип итеп күз алдына китергәннәр. Аларны махсус рәвештә җитешсез итеп ясаганнар. Бар җирләрен дә камил итеп ясасаң, алар терелергә һәм исәннәргә зыян китерергә мөмкин дип уйлаганнар.



*Мөгезле барс формасындагы йозакка атланган җайдаклар*

Болардан тыш борынгы Болгар илендә барс формасында эшләнгән йозаклар да күпләп табыла. Барслар «циркуль» орнаменты белән бизәлгәннәр. Мондый бизәк болгар әйберләрендә еш очраса да, бу очракта алар ярдәмендә рәссамнар алмачуар тиреле барсларны сурәтләргә теләгәннәрдер. Ала яисә чуар барс борынгы төрки мифологиядә аеруча изге итеп сурәтләнә.

Болгарда барс сыннарының барысы да диярлек сыңар мөгезле итеп ясалган. Бу үзенчәлек хәтта болгар-татар акчаларында да чагыла. Димәк, болгар барсы гади генә түгел, мөгезле. Ә мөгез башкалардан аерылып тору билгесе булган. Әйтик, борынгы һуннарда бәкләр исемендә кешенең дәрәҗәсен (титулын) күрсәтә торган «дүрт мөгез», «алты мөгез» кебек компонентлар кулланылган. «Берәү дә мөгезле булып тумый» дигән халык мәкале шул нигездә туган. Мифларда мөгезгә ия булу бәхетне, дәрәҗә һәм хакимлекне белдерә. Татарлар, мәсәлән, еланнар патшасы ак еланның бәхет китерүче мөгезенә ышаналар. Урман иясе атаклы Шүрәле дә бер мөгезле. Төрки халыкларда киң таралган риваятьләрдә бәян ителгәнчә, патшалар патшасы Александр Македонский (ислам дөньясында ул Зөлкарнәйн дип йөртелгән, ә «Зөлкарнәйн» сүзе «ике мөгез» дигән мәгънәне аңлата) да мөгезле булган, имеш.

Ни өчен бу йозаклар табына торган сын – барс кыяфәтендә ясалган соң? Борынгыларның дөньяга карашыннан чыгып фикер йөрткәндә, йозакка бикләнгән әйбер яисә йорт-җирнең иминлеген тотем гына тәэмин итә алган. Алай гына да түгел, ил-йортның, халыкның ышанычлы сакчысы булып тотем – барс хезмәт иткән. Болгар илендә барсны үзенең тотемы дип таныган кабилә яшәгән. Бу – иң көчле болгар кабиләләреннән саналган барсил кабиләсе. «Барсил» сүзе «Барс иле», «Барс кешеләре» дигән мәгънәне аңлата. Барс кабиләсе – болгар кабиләләренең иң борынгысы. Барсиллар Үзәк Кавказ алды Һун берлегенең көчле бер кабиләсе буларак билгеле. Хәзерге Дагстан җирендә, Каспий буйларында урнашкан бу дәүләтне шул чор чыганаклары Барсилия (Берсилия) дип атыйлар. Хәзәр каганлыгы да шуннан оешып киткән.

Яңа туган балага тотем хайван исемен кушу ул дәвердә гадәти хәл саналган. Шуның белән борынгылар балага тотем көчен бирергә теләгәннәр, болай эшләгәндә аны тотем үз яклавы астына алачак дип уйлаганнар. Барс исеме белән бәйле исемнәр дә борынгы төрки чорда ук очрый. Төрки каганлыгының аксөякләре арасында да ул шактый еш күзәтелә. Алар Урхун-Енисей язмаларында да урын алган: Барс бәк, Ирбис. Бу сүзләр «кар барсы» дигән мәгънәне белдерә. Тагын Ирбис Ышбара (кодрәтле барс), Ирбис Ышбара Җабгу хан, Ирбис Дулу хан, Баһадур Ирбис хан, Ирбис Шегуй хан кебек исемнәр була. Ә «барс» компоненты белән ясалган кеше исемнәре татарлар арасында хәзер дә кулланыла: Айбарс, Байбарс, Бибарс, Илбарс, Колбарс, Янбарс һ.б.

Тотем гасыр дәвамында үсеш-үзгәреш кичерә. Башта хайван баба изгеләштерелсә, аннары – хайван баба белән кеше баба хасиятләрен берләштергән ыру башлангычы, соңыннан кеше баба зурлана.

Татарстан гербының үзәгендә дә борынгы барс сыны ясалган. Ул үзендәге сыйфатлар белән халкыбызны яхшы тормышка әйдәп баруда, аның адымнарына ышаныч бирүдә, иминлегебезне, азатлыгыбызны саклауда рухи нигез буларак күзаллана.

**Игезәкләр турындагы мифлар.** Борынгы кеше өчен игезәк бала туу

гадəттəн тыш хəл саналган. Алар игезəклəрнең тууында табигый булмаган көчлəрнең катнашы бар дип уйлаганнар. Мондый балалар башка кешелəрдə булмаган (табигый булмаган) көчкə, сəлəткə ия дип ышанганнар. Алар теге яки бу əйберне, күренешне барлыкка китергəн «культура геройлары»на əйлəнгəннəр яисə ыру-кабилəнең башлангычында торучы борынгы бабалар булып саналганнар.

«Нух улы Яфəснең Газый, Төрек һəм Алып исемле уллары булган» дип сөйлəнелə борынгы заманнардан килеп җиткəн бер риваятьтə. Бервакыт, шайтан котыртуы буенча, алар арасында талаш башлана һəм сугыш кабынып китə. Нəтиҗəдə Газый Төрек тарафыннан җиңелə. Төрек, җиңүче булса да, бу Алла каргаган җирдəн ераккарак китүне артыграк күрə. Ул Алып белəн бергə ерак салкын илгə – зур елга буена килеп урнаша. Мондагы җирлəр сазлыклар һəм карурманнар белəн капланган була. Бу урыннардан барганда, Алыпның чабатасы вакыт-вакыт пычрак яки тузан белəн тула һəм Алып аны юл уңаена кагып бара. Шул каккан балчыктан кечкенə түгəрəк калкулыклар барлыкка килə.

Бервакыт Алып ауда бик еракка китеп адаша да туганы Төрек янына кайту юлын таба алмый. Менə ул бик зур елга – Əтил (Идел) буена килеп чыга. Ауда йөргəндə, Болгар чиклəрендə уртача һавалы, чəчəк атучы сəхрəлəр, кеше аягы басмаган урыннар күреп, шунда урнашып кала. Бу елга буенда Алып телен белүче кешелəр яши икəн. Лəкин алар бөтенлəй башка ырудан булалар. Алып шунда яшəп кала һəм җирле кабилəлəр арасыннан бер кызга өйлəнə, аларның игезəк уллары туа. Алып аларга Болгар һəм Бортас дигəн исемнəр куша. Үсеп җиткəч, Болгар – Болгар шəһəренə, Бортас Бортас шəһəренə нигез сала һəм алар шунда яшəп калалар. Төлке, кеш, ас, тиен аулыйлар һəм тирелəреннəн кием тегəлəр. Тора-бара бу ике шəһəрнең халкы ишəя һəм бер ырудан чыккан ике халык барлыкка килə. Бу инде – кеше баба хакындагы мифологик хикəят.

**Календарь мифлар** – үлеп терелгəн табигать турындагы мифлар. Яз җиткəч, табигать терелə, уяна; җəен чын яшəү чорын кичерə; көз көне уңыш белəн тула. Əмма көз – табигать яшəешенең соңгы чоры да. Шуннан соң табигать йокыга тала – кыш килə. Аннан соң, кабат яз килеп, табигать янə уяна, яшəрə һəм бу мəңге шулай дəвам итə.

Əмма Җир шарының төрле җирендə климат төрлечə. Бер фасылдан – йə җəйдəн, йə яздан, йə кыштан гына торган урыннар да бар. Ə безнең якларның бик борынгы заманнардан бирле яз дисəң – чын язы (табигать йокыдан уянып **языла**, киерелə), җəй дисəң – чын җəе (табигать **җəелə**), көз дисəң – чын көзе (табигать җыерыла, «**көзəн** җыеру» гыйбарəсе шуннан килеп чыккан), кыш дисəң – чын кышы (табигать **кысыла**) бар. Кыш җитсə, җəйне сагына башлыйбыз, җəй җитсə – кышны. Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай əйтмешли, һавабыз шундый:

Анда бик салкын вə бик эссе түгел, урта һава;
Җил дə вактында исеп, яңгыр да вактында ява.

Мондый мифлар календарь йолалары белән тыгыз бәйләнештә туа. Беренче чиратта ул аграр магия белән бәйле. Аның нигезендә ел фасылларының алмашынуы ята. Бу йолаларның барысы да мул уңыш өчен эшләнә. Борынгы төрки бабаларыбызның беренче календарьлары да ел буена даладагы үләннең төсе үзгәрүенә, хайваннардагы үзгәрешкә нигезләнгән. Борынгы төркиләр яшәешләрен һәм вакыт хисабын «дөнья яратылган көннән» башлаганнар. Иксез-чиксез далаларда үсеп утырган үләннең төсе үзенә күрә бер календарь ролен үтәгән. Көз яисә кышка таба үләннәр саргая. Язын яшәрә, җәен чәчәк ата. Шулай да табигый шартларда алар кинәт кенә яшел төскә керми яисә тиз генә корып саргаймый. Бу үзенчәлек елны тагын да ваграк өлешләргә бүләргә мөмкинлек бирә. Шулай ук борынгы күчмә халыклар вакыт ориентирлары итеп алырлык дала табигатендәге, малтуар, хайваннар тормышындагы башка нечкәлекләрне дә белгәннәр. Борынгы төрки рун язмаларында җәй ае (июль) яки болан тауларда йөгергән ай (август) турында мәгълүматлар бар.

Ел саен бер үк вакытта үткәрелә торган йолалар да кеше аңында уелып калган. Алар аша борынгы кешеләр вакытны барлаганнар. Андый йолаларны башкарып, дөнья яратылган вакытка кайткан кебек булганнар. Аерым ритуалларны үтәп, аннан соң булган вакыйгаларны тасвирлаганнар.

Борынгылар яңа елны яздан башлаганнар. Башта яңа елны, язны каршы алу йолалары, аннары көзен уңыш бәйрәме, аннан тагын яңа елны каршы алу... Шуңа күрә дә вакыт шундый нокта-ориентирлар – бәйрәм, йолалар аша әйләнә буенча хәрәкәт кебек каралган. Алар карашынча, мондый йола-бәйрәмнәр кешеләр тормышын тәртипкә сала торган Вакытны саклап калганнар, ыгы-зыгыга, тәртипсезлекнең, хаосның кире кайтуына юл куймаганнар. Борынгы кеше өчен боларның һәммәсе тормышның үзе кебек зур әһәмияткә ия булган.

Аучылык белән шөгыльләнгән халык буларак, борынгы кешеләр хайван календарен уйлап табалар. Бу календарь кытай, төрки-монгол халыкларында киң таралган. Аның (этиологик мифларның) ничек барлыкка килүе хакында да легендалар таралган: «Төркиләр ханы үзенә кадәрге бер сугышның кайчан булуын белергә уйлаган. Әмма сугыш елын төгәл ачыклый алмаганнар. Хан, киләчәктә мондый билгесезлекләрне булдырмас өчен, унике айга, унике йолдызлыкка нигезләнеп, унике еллык календарь төзергә боерган һәм, һәр елга исем кушар өчен, киек-җанварларны зур суга куарга кушкан. Унике хайван елганы кичеп чыкканнар. Елларны, хайваннарның суны нинди тәртиптә кичүләренә карап, шул хайваннар исеме белән атаганнар».

*Хайван календаре басылган җиз болгар дискы*



Төркиләр арасында бу легенданың башка вариантлары да билгеле булган. «Имештер, борын-борын заманда кешеләр ел исәбен төрле хайван исемнәре белән алып барырга булганнар. Бу хәбәр тизлек белән җәнлекләргә дә барып җиткән, һәм алар арасында шау-шу куптарган, ди. Барысының да



*Унике еллык хайван календаре барлыкка килү турындагы легендага иллюстрация. Заһир Хәкимов рәсеме*

календарьның беренче елына үз исемен бирәсе килгән. Озак бәхәсләшкәннән соң, наян Тычкан болай дигән: «Мондый талаштан берни дә чыкмас. Без елның килгәнен карап-күзәтеп торыйк, кайсыбыз алдан күрсә, шул ел башы булыр». Үзе астан гына Дөягә күз кыса, ди. Дөя Тычканның хәйләсен сизмәгән. Буе озын булгач, елның килгәнен алданрак күрермен дип уйлап: «Әйе шул, Тычкан, кечкенә булса да, дөрес әйтә: кем беренче күрә, шул ел башы булыр», – дип, аның сүзен куәтләгән, ди. Шул сүзгә барысы да күнеп, барысы да елның килгәнен күзәтеп карап тора башлаганнар. Тычкан шул арада анда йөгергән, монда йөгергән дә, кинәт Дөя өстенә атылып менеп, өркәченең башына ук менеп утырмасынмы?! Әлбәттә, елның килгәнен барыннан да элек ул күреп алган. Шунда ук калганнарына хәбәр дә биргән, ди. Шул рәвешле елның башы булып калган. Башка хайваннар Дөягә: «Син Тычканны үз аркаңа утырткач, икегез дә бер исәптә», – дип, аны исемлектән сызып ук ташлаганнар. Ул шушы кадәр зур буе, озын муены белән унике хайван исемлегенә керә алмый калган. «Дөя, буена ышанып, коры калган» дигән гыйбарә шуның бер чагылышы, имеш».

«Вакыт – Күк (Тәңре) карамагында, кеше балалары барысы да үләр өчен туганнар» диелә борынгы төрки язмаларда. Чыннан да, һәркем кайчан да булса җир тормышыннан китәчәк. Дәһшәтле Вакыт барысын да йота. Кайчандыр Александр Македонский, Чыңгыз хан империяләре булган; Җир шарының алтыдан бер коры җирен биләгән, мәңгелек булып тоелган СССР яшәгән һ.б. Аларны бик күпләп санарга мөмкин. Әмма барысын да Вакыт йоткан. Тормышка мәңгегә килгәндәй кыланып, күп бәла-казалар китергән, меңнәрчә, йөз меңнәрчә кешеләрнең газиз җаннарын кыйган тираннарны, императорларны да Вакыт йоткан. Борынгы грекларда хәтта аерым Вакыт алласы да булган. Аның исеме – Крон. Әлеге исемгә нигезләнеп ясалган «хронология», «хронометр» кебек сүзләрне бүген үзебез дә еш кулланабыз. Крон бернәрсәне дә – хәтта үз балаларын да кызганмаган. Хатыны Рея балаларны тудыра торган, әтиләре Крон аларны йота барган. Кансыз, таш күңелле Крон бар нәрсәне барлыкка да китергән, юкка да чыгарган.

**Героик мифларда** батырның тормыш тарихы гәүдәләнә. Аның тылсымлы тууы, өлкән туганнары яки коточкыч җан ияләре (дию,

аждаhа) белән көрәше, үзенә кәләшлеккә кыз эзләве, бу юлдагы көрәш-маҗаралар сурәтләнә. Булачак батырлар гади кешеләр сыман гына тумыйлар. Әниләре кояш нурыннан йә булмаса күктән авызына төшкән боз бөртегеннән балага уза яисә балалары булмаган ир белән хатын булачак батырны камырдан ясыйлар. Ул кечкенәдән бик көчле булып үсә. Дию пәрие урлап китеп җир астына (мәгарәгә) яшергән кызны табып алып кайта, аңа өйләнә. Бу юлда бик күп җәфа чигә. Дию пәриенә каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәтә. Исегезгә төшкәндер, мондый сюжетлы әкиятләрне сезнең укыганыгыз бар. Алар арасында «Таң батыр», «Камыр батыр» кебекләре бик борынгы чордагы фикер-карашларны чагылдыра. Алар беренче кешелек җәмгыяте таркала башлаган чорга – бердәм ырудан көчле шәхесләр аерылып чыга башлаган вакытка карый.

**Эсхатологик мифлар** дөньяның бетүе, кыямәт көненең якынлашуы хакында сөйли. Борынгы кеше тәртипкә китерелгән дөнья беренчел халәтенә – хаоска кайта дип уйлаган. Мәсәлән, Библиядә һәм Коръәндә болай хикәяләнә: «...Берзаман, коточкыч мәхшәр кубып, бөтен җирне су баскан. Нух пәйгамбәр, моны алдан күреп, зур көймә төзеткән һәм дөньядагы бар җан ияләреннән берәр парны көймәсенә алган. Шул рәвешле кешелекне, табигать дөньясын коткарып калган. Шуннан соң кешелек тарихы яңадан башланган. Нух пәйгамбәр кешеләргә яшәү кануннарын өйрәткән. Шул рәвешле төркиләр үзләренең килеп чыгышларын Нух пәйгамбәрдән башлаганнар.

Беренчел культурага синкретизм хас. Шушы сыйфат фикерләү рәвеше белән идеологиядә дә урын алган.

## ДИН

Мифлар белән дин борынгы заманнан ук тыгыз бәйләнештә яшәгән. Алда әйтеп үтелгәнчә, мифның диннән аермасы шунда: мифка, анда бәян ителгән шәхесләргә һ.б.ларга табынмыйлар. Диннең иң борынгы төрләре булып тотемизм, фетишизм, анимизм һәм магия санала.

Көнчыгыш Бирмадагы «хатын-кыз жирафлар»





**Тотемизм** – диннең иң борынгы төре. Төньяк Америка индеецларының алпоки кабиләсе телендә ул «абыем яки сеңлем белән туганлык» дигән мәгънәне аңлата. Әмма монда «абый» һәм «сеңел» төшенчәләре кешене түгел, бәлки хайван яки үсемлекне күз алдында тота. Тотемизм ул – табигать күренешләрен ырулык мөнәсәбәтләренә күчерүнең конкрет чагылышы. Борынгылыкта ул ыру әгъзалары белән тотем (хайван яки үсемлек) арасында туганлык турындагы карашларга бәйле ышанулар һәм йолалар комплексын аңлаткан. Гадәттә һәр ыруның исеме тотем исеменә туры килгән. Тотемны үтерергә яки ризык буларак кулланырга – ашарга ярамаган. Борынгы кешеләр гадәттә тотем итеп тормышларында әһәмиятле урын тоткан хайванны сайлаганнар. Бу азык-төлек чыганагы булган хайваннарга да караган. Әмма мондый терлекне аулау тыелган, чөнки ыру ачтан үлеп бетәргә мөмкин. Шунлыктан борынгылар, тотем хайванның күңелен күреп, аннан гафу үтенгәндәй, төрле йолалар башкарганнар. Табына торган хайван ыруның башлангычы һәм саклаучысы булган. Аның күңелен күрергә теләп, ыру кешеләре корбан китергәннәр, төрле йолалар үтәгәннәр, бәйрәмнәр уздырганнар.

Эстетик карашлар да тотемистик фикерләүләр белән үрелгән. Кешеләр үзләре ук тотемга охшарга тырышканнар. Ир-атлар көч, җитезлек белән, хатын-кызлар йөз-кыяфәт белән тотемны кабатларга омтылган. Жираф тотем булган җирләрдә

муеннары бик озын хатын-кызлар матур саналган. Моңа ирешү өчен кыз баланың муенын яшьтән металл кыршаулар кидереп озынайтканнар.

Ыру башлангычы итеп бегемотны санаган кешеләр аскы иреннәрен салынып төшәрлек дәрәҗәгә җиткергәннәр. Дөньяда моңа охшаш мисаллар тагын да бар.

Ырулар берләшкәндә, кешеләр акылында бу ыруларның тотемнары булган хайваннарның кыяфәтләре дә үзара кушылган. Шуннан сәнгатьтә зооморф, ягъни «эт – баш, сыер – аяк» кебек хайван рәсемнәре дә барлыкка килгән. Ә кабиләләр таркалганда, киресенчә, тотем сурәте дә, аның исеме дә бетәргә тиеш булган. Аерылган ыру төп тотемның нинди дә булса бер әгъзасын яисә төсен үзенә алган. Мәсәлән: Ак бүре, Кашка тәкә, Каз аяк һ.б.

Тотемнар турындагы карашлар үсешендә кызык кына хәлләр дә килеп чыга. Мәсәлән, бик борынгы заманнарда семит телле (гарәп, яһүд һ.б.ларның бабалары) халыклар үсешләренең бер чорында дуңгызны тотем баба дип санаганнар. Аның итен ашау тыелган. Яңа, сыйнфый җәмгыять диннәренә күчкәндә, аучылар өчен табу булган мондый тотем хайваннар изгеләштереләләр яки, киресенчә, нәҗескә, шайтанга әвереләләр. Дуңгыз белән дә шулай килеп чыга: мөселманнар һәм яһүдләр аны нәҗес дип игълан итә. Тотемлы ырулык җәмгыятенең ыруларга таркалуы табигать, хайван алласыннан кеше алласына күчүгә, Алла әфәнденең пәйда булуына китерә. Әмма беренче кешелек җәмгыятендә барлыкка килгән карашларның көче шунда да: тотемистик караш калдыклары бүгенге көнгә кадәр килеп җиткәннәр. Алар: ниндидер хайванның, кош-кортның итен ашаудан тыелу, аның әгъзаларын халык медицинасында файдалану (шулай итеп тотем көчен алырга омтылу), аны саклану чарасы – бөти рәвешендә файдалану, аерым хайваннарга багышланган йолалар, гореф-гадәтләр һ.б. Элек татарлар поши кебек хайваннарны, торна, аккош, сыерчык кебек кош-кортларны үтерүне зур гөнаһка санаган, Тәңрегә корбан итеп биргән хайваннарны изгеләштергән һ.б.

Һуннар, борынгы төркиләр динендә тотемистик карашлар да киң урын алган. Борынгы төрки җәмгыятьнең аксөякләр катламы үзләренең чыгышларын ниндидер җанварга тоташкан легендар бабалар культы белән бәйләгәннәр. Кагыйдә буларак, аларга үз исеме белән бергә хайван исемен дә кушканнар.

Билгеле булганча, хайван культы бик борынгы заманнарда, борынгы кеше әле үзен табигатьтән аерып карамаган, аңа каршы куя алмаган, бар ыру-кабилә мөнәсәбәтләре һәм кеше үзен дә хайваннар белән тиңләштергән чорларда барлыкка килгән. Борынгы кеше тирә-юньне үзенә бик якын һәм аңлаешлы булган ыру-кабилә мөнәсәбәтләре аша танып белгән һәм аны табигатькә, шул исәптән хайваннар дөньясына күчергән. Әмма борынгы төркиләрдә тотемизм калдыклары, нигездә, традиция буларак кына сакланган. Аның реликтлары мифларда, генеалогик легендаларда чагыла. Боларда ыруның, кабиләнең килеп чы-

гышы аерым бер хайван белән генә бәйләнешле түгел, ә бәлки хайван баба белән кеше баба синтезында карала.

Гомумтөрки бүре культының тамырлары бик борынгы заманнарга китә. Күчмә мал асраучылык белән шөгыльләнгән халыклар тормышында бүре зур роль уйнаган. Борынгы Кытай чыганакларына күз салсак, төрки атлы гаскәрләрнең иң яхшылары «бүреләр» дип йөртелгәнен күрербез. «Аларга күк көч биргәнгә күрә, минем атам каганның гаскәре бүре кебек» диелә борынгы төрки язмада. «Бүре» сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында да киң кулланылган. Моны аеруча затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була.

Бу традиция соңрак та дәвам итә. Азов болгарларының атаклы хакиме Кубратның исеме аерым чыганакларда Курт яисә Корт дип укыла. Бу – бүренең борынгы төркичә әйтелеше. Хәзерге татар телендә ул сүз әлеге мәгънәдә «кош-корт», ягъни «кош-җанвар» сүзендә генә сакланып калган. Бу очракта «корт» бар җанварларның вәкиле, башлыгы кебек тә аңлашыла. Ашина төркиләренең байракларында бүре башы сурәтләнгән булган, «түрк ханы» һәм «бүре» сүзләре бер төшенчәне белдергән. X–XII гасырларда угыз-кыпчакларның тотемы бүз бүре булган. Нәсел башы дип уйланылган җанвар, борынгы кеше фикерләвенчә, аның бөтен тормышында әһәмиятле роль уйнаган. Көтүләрнең исән-сау булуы, үрчүе дә, ауның уңышлы яки уңышсыз булуы да, явыз көчләрдән, табигать стихияләреннән саклану да тотем бабаның ни дәрәҗәдә күңелен күрүгә бәйләнгән.

Бүре культының эзләре Идел, Урал буйларында табылган археологик ядкәрләрдә дә күренә. Борынгы башкорт курганнарында бүре бите формасындагы көмеш битлекләр очрый. Борынгы кешеләр, гүр иясенә шундый битлек кидереп, шул рәвешле тотемга хас кыяфәт, көчкодрәт биреп, аның теге дөньяда хәвеф-хәтәрсез гомер кичерүен теләгәннәр. Бу гади кеше генә түгел, янәсе, ә бар нәрсәдән дә көчле Бүре ыруыннан. Борынгы болгарларның Олы Тархан, Танкеевка, Салтау каберлекләрендә табылган бүре тешләре дә шул хакта сөйли. Аны бөти итеп тагып йөргәннәр. Каберлекләрдә бүре тешеннән тезелгән муенсалар да очрый. Әлбәттә, аларга бүре тешен яисә бүре тырнагын табу җиңел булмагандыр. Шуңа күрә аның тешен яисә тырнагын хәтта бронзадан коеп та такканнар. Бу хәл бүре тешләре яисә тырнакларының саклау көченә бик нык ышанган очракта гына мөмкин. Бөек бүренең үзе өчен дә иң үтемле саклану чаралары аның тешләре һәм тырнаклары бит.

Татар халкының борынгы бер тотемы Ак бүре булган. Безнең көннәргә килеп җиткән бер риваятьтә сөйләнелгәнчә, татарларның борынгы бабалары таулы, урманлы җирләрдән күченеп барганда адашалар. Шул вакыт аларны дошманнар уратып ала. Үлем котылгысыз кебек була. Шулчак каяндыр Ак бүре килеп чыга һәм аларны яшерен юллар белән чолганыштан алып чыга. Бу сюжет кайбер үзгәрешләр белән борынгы төрки чорлардан ук килә.

«Ак бүре» исемле татар халык әкиятендә бүре кеше кыяфәтенә дә керә һәм башка кош-корт яисә хайваннарга да әйләнә ала. Ул әкият каһарманына ярдәм итә, үзенә ошамаган кешеләрне исә таш сынга әверелдерә.

Татар фольклорында бүре гадәттән тыш кодрәтле, буе 60 метрга кадәр, зур итеп тасвирлана. Бүренең көче, зурлыгы легендар гомумтөрки фольклордагы Алып белән тиңләштерелә.


Моннан тыш Ак бүре элек татарларда халык авыз иҗаты әсәрләрен теләсә кайчан, вакытлы-вакытсыз куллануны тыйган. Көндез әкият сөйләү, табышмак әйтү рөхсәт ителмәгән. «Көндез әкият сөйләгән кешене ак бүре ашар» яки «Табышмакны көндез әйтсәң, ак бүре очрый» дип куркытканнар.

Татарлар карт бүре улавын еллар иминлегенә юраганнар. Каракның кем икәнлеген белү өчен бүренең сеңерен утта яндырганнар, шуның белән җинаятьченең кул-аягы тартыша, кибә дип уйлаганнар. Шунысы кызык: бүре культы Дунай болгарларында да сакланып калган. Бүрегә багышлап, алар бәйрәм үткәргәннәр. Аның сынын бронзадан койганнар. Болгар патшасы Симеон улы Баян (IX гасыр) бүре кыяфәтенә керә алган, имеш.

Борынгы төркиләрдә, хәзәр-болгарлардагы кебек үк, кыпчак ханнары борынгы патриархаль ыру аксакаллары төсмерен югалтмаганнар. Алай гына да түгел, Кыпчак җәмгыятенең иң югары руханилары булып саналганнар. Һичьюгы XI гасырда әле бу шулай булган. Рус елъязмалары Боняк ханның, сугыш башланыр алдыннан рухлар белән элемтәгә кереп, сугыш нәтиҗәсен үз файдасына хәл итәргә омтылуы хакында язалар. Имеш, ул төнлә, урдадан читкә китеп, бүреләр белән сөйләшкән (улаган).

Күчмә, мал асраучы кабиләләрдә бүре культы белән беррәттән этне дә изгеләштергәннәр. Кайбер генеалогик риваятьләрдә ул кабилә башлангычы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Мәсәлән, кыргызлар үзләренең иң борынгы бабалары итеп Кызыл этне санаганнар. Эт күп кенә кыпчак ыруларының да тотемы булган. Кыпчак аксөякләре дә, үзләренең шундый генеалогияләре белән горурланып, балаларына эткә бәйләнешле исемнәр кушканнар. Мәсәлән, Кобәк, Кончак кебек күренекле кыпчак бәкләренең исемнәре дә эт белән бәйләнгән.

*Мөгезле тәкә башы рәвешендәге керамик сусипкеч*



Үгез дә борынгы төрки культлардан санала. Угыз кабиләләренең исемнәре дә, легендар Угыз каган исемнәре дә тотем хайван исеме белән туры килә. Угыз каган борынгы төркиләрнең бабасы буларак тасвирлана.

Борынгы төркиләрдә иң культлаштырыла торган һәм Тәңрегә, Күккә, Кояшка иң кулай корбан хайваннардан тәкә саналган. Аның культы алга таба да дәвам итә. Ул болгар, угыз, кыргыз кабиләләрендә дә изге хайван булып йөри. Потка охшаш тәкә сыннары болгар археологик

материаллары арасында еш табыла. Шулар арасыннан зур мөгезле тәкә башы формасында ясалган куыш керамик фигура игътибарны үзенә җәлеп итә. Аның табигый мөгезләреннән тыш тагын ике мөгезе бар. Гомумән, бу – дәһшәтле, беркадәр куркыныч сын. Күрәсең, ул табына торган сындыр. Аның өстәмә мөгезләре булу шуны раслый.

Уңыш яңгырның вакытында яву-яумавыннан да тора. Корылык булганда, борынгы бабалар «Яңгыр боткасы» йоласын уздырганнар. Тәңрегә корбан итеп, яңгыр болытларына охшаган кара тәкә, сарык суйганнар. Тәкә башына охшаган керамик сусипкеч әлеге йоланың бер магик инструменты булган. Аның ярдәмендә яңгыр чакырганнар. Кешеләр аның белән бер-берләренә су сибешкәннәр. Үзләре түбәндәге җырны җырлаганнар:

Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Илгә ачлык килмәсен,
Ачтан халык үлмәсен,
Чума чире йөрмәсен!

Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Иген-ашлык күп булсын,
Башаклары тук булсын,
Кибән-эскерт зур булсын!


Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын;
Сөтле сыер абзарда, –
Бар да булыр яуганда,
Яңгыркаем, яу, яу, яу!

Телебездәге «Алланың кашка тәкәсеме әллә син?!» дигән гыйбарә дә тәкәнең борынгылыкта Тәңрегә нисбәтле хайван булуы һәм аның культы хакында сөйли («Әллә кем булып кыланасың, Алланың кашка тәкәсеме әллә син?! »).

Борынгы бабаларыбыз Тәңрегә кашка (йолдыз) тәкә корбан иткәннәр. Икенче төрки династиянең (683–744) (шул ук вакытта Икенче төрки каганлыкның да) геральдик билгесе башы ромб формасында ясалган кәҗә тәкәсе сурәте булган. Мондый сурәт Капаган каганга куелган дип уйланган мемориаль комплекстагы ташбака сыны янәшәсенә ясалган.

Татар халкында Күк тәкәсенә (борынгы мәгънәдә – «Тәңре тәкәсе») ышану яшәгән. Аңа махсус җыен багышланган («Күк тәкә» җыены).

Вакыт ягыннан караганда, тотемизмнан соң **фетишизм** (португал телендә fetiso «амулет» мәгънәсен белдерә) килә. Ул – җансыз әйберләрне изгеләштерә, аларга табына, гайре табигый хасиятләр бирә торган дин. Борынгы кеше мондый җисемнәр авырулардан, явыз көчләрдән, бәла-казалардан саклый, көнкүреш-



*Пот-фетишлар. XIX гасыр гравюрасы*




*Кәгъбә – табыну урыны*

тә ярдәм итә дип ышанган. Теләсә нәрсә фетиш була алган. Әйтик: хайван теше яисә хайван тырнагы, үзенчәлекле формадагы таш, төймә һ.б. Күп очракларда бу фетишлар саклагыч бөти итеп тагып йөртелгән. Без хәзер дә укый торган тылсымлы таяк, кылыч, каурый хакындагы әкият һәм легендаларда шул турыда сөйләнә.

Фетишизм күренешләре дөньядагы барлык диннәрдә дә очрый. Мәсәлән: христианнарның тәре тагып йөрүе, иконаларга табынуы, мөселманнарның Кәгъбәдә саклана торган кара ташка ышанулары һ.б.

Без әле дә кайбер әйберләрнең тылсым көченә ышанабыз: йортка бәхет китерер өчен ишек өстенә дага асабыз; имтиханга барганда, үкчә астына биш тиенлек акча куябыз һ.б. Борынгы кешеләр кебек үк уңышка, бәхеткә ирешәсебез килә. Ә борынгы кеше өчен бу бердәнбер юл булган.

Борынгы диннәрнең чираттагы баскычы – **анимизм** (латин телендә anima, animus «рух», «җан» мәгънәсен аңлата). Ни өчен анимизм дин үсешендә тотемизм һәм фетишизмга караганда соңрак баскыч санала соң? Чөнки бөек рух, тәнсез җан турындагы карашлар туу өчен кешенең гомумиләштерелгән төшенчәләрне аңлавы, абстракт фикер йөртә белүе кирәк. Иң борынгы кеше әле абстракт төшенчәләрне аңламаган.

Аның өчен тормышта күз күрмәгән, колак ишетмәгән, тән тоймаган әйбер булмаган. «Җан», «бәхет», «үлем», «яшәү» кебек төшенчәләр бары конкрет гәүдәләнештә генә кабул ителә алган.


Элек тормышны – елга; бәхет һәм җанны – кош h.б. белән тиңләштерү яшәгән. Димәк, анимизм ул – тәнсез җанның яшәве, аның көченә ышану, кеше белән тәнсез җанның, рухларның үзара аралашу мөмкинлегенә инану. Ул борынгы кешеләрнең табигатьне җанландыру, сынландыруыннан килеп чыккан. Янәсе, күз күргән дөньядан тыш күренми торган рухлар, җаннар дөньясы бар. Алар явыз һәм яхшы җаннарга бүленә. Явыз җаннарны кешегә зыян китермәслек итеп үзгәртергә, яхшыларыннан ярдәм сорарга, ә моның өчен барысының да күңелен күрергә, корбан китерергә кирәк.

Күмү йолалары да борынгыдан ук үлгәннән соң җанның мөстәкыйль яшәвенә, аның мәңгелегенә ышану белән бәйле. Алар дин барлыкка килгәндә үк оеша. Бу йолалар төрле халыкларда төрлечә үткәрелә һәм гаҗәеп күптөрле була.

Күмү йоласы ул – борынгы кешенең үлемгә мөнәсәбәте дә. Үлем, борынгы кешеләр фикеренчә, гадәти тормышның бозылуы. Бу – трагедия, катастрофа. Кеше тормышы ниндидер гайре табигый көчләрнең тәэсире белән өзелә. Борынгылар, үлем дигән афәтне булдырмас өчен, төрле йолалар үткәреп, бу фаҗигадән сакланырга тырышканнар. Алар үлемгә дучар булган кешедән курыкканнар һәм аны ырудан араларга омтылганнар. Бер үк вакытта икенче караш та яшәгән. Ыруның тулылыгын тәэмин итәр өчен үлгән кешене исән кешеләргә якын урында сакларга кирәк булган. Янәсе, исән кешеләр карамагында булганда, ул әллә ни зыян китерә алмаячак. Беренче каберләр таш гасырына карый (кешелек үлгәннәрне күмү йолаларын бик соң куллана башлаган). Еш кына үлгән кешеләр үзләре яшәгән мәгарәләрдә үк күмелгән.

Без мәктәп дәреслекләреннән Үзбәкстандагы Тишек Таш мәгарәсендә күмелгән борынгы малай

*Неандерталецны (Ле-Мустье) күмү*



каберен беләбез. Дөнья халыклары бик күптөрле күмү йолаларын кулланган, дидек. Әйтик, үлгән кешене кая да булса кую: җир өстендә калдыру, җир астына күмү, агачка асу, су астына төшерү, яндыру һ.б. Җирләү дә борынгыдан ук бик күптөрле үзенчәлекләр белән аерылган. Кеше күмеләчәк чокырның формасы, тирәнлеге, кабер өстенә куела торган корылмаларның нинди булуы, үлгән кешенең чокырга ни рәвешле яткырылуы һ.б. Мәсәлән, күчмә төрки халыкларга зур-зур курганнар төзү хас. Археологик яктан һун курганнары бик күренекле. Инде рус сүзенә әйләнгән «курган» сүзе төрки-татар «корган» («төзелгән») сүзеннән килеп чыккан. Алар мәһабәт һәм катлаулы төзелешле. Һун аксөякләре курганнарының диаметры 100 метрга, биеклеге 10 метрга җитә. Курганнар астындагы каберләр дә бик тирән: 10–15 метр. Мәетләр зур байлык белән бергә күмелгән. Нәкъ шуңа күрә, курганнарның биеклегенә, каберләрнең тирәнлегенә дә карамастан, йөзәр еллардан соң бу курганнар һәм аларда күмелгән байлык рус казакларының табышына әверелгән.

Дөньядагы җиде могҗизаның берсе – борынгы Мисыр фиргавеннәре күмелгән пирамидалар. Әлеге күмү йолаларының һәрберсе үзенә күрә бер ышану белән бәйләнгән. Мәсәлән, үлекне яндыруда саф җанны, нәҗес тәннән аерып, тизрәк илаһи дөньяга – күккә күтәрергә омтылыш күренә. Телебездә хәзер дә сакланган «көлен күккә очыру» гыйбарәсе бик борынгы бабаларыбызның үлекне яндыру йоласы белән таныш булулары хакында сөйли.

*«Тормыш агачы» сурәте төшерелгән таш калып*



«Күк», «дөнья», «галәм», «тормыш агачы» кебек төшенчәләр җанның бакый дөньяга китү чарасы буларак кабул ителгән. Алар – кеше җанының туганчы һәм үлгәч урнашу урыны да саналган. Шушы караш нигезендә болгарларда «агачка күмү» йоласы да булган. Болгарлар акылы, гайрәте белән аерылып торучыны, Тәңрегә хезмәт итәргә иң яраклы кеше дип, агачка асып куя торган булганнар. Шундый ышану нигезендә бер һиндстанлыны бик биек агач башына (Тәңрегә «якынрак» урынга) асулары билгеле. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Фазлан да төньяктан килгән алып скелетын бик зур агачка асылган хәлдә күрүе турында яза.

Мондый күмү йоласы үзенең тамырлары белән борынгы төрки чорларга барып тоташа. Бу йола һуннардан ук килгән. Үлгән кеше өч ел агачта асылынып торганнан соң, аның сөяген җыеп яндырганнар. Ибне Фазлан язмаларына караганда, төньяк алыбының гәүдәсе дә шактый гомер агачта асылынып торган: «Яңгыр һәм кояшның эшенә дучар булганчы... Заман узу белән, җил очыртып бетергәнче». Сәяхәтче аның тарала башлаган скелетын гына күрә.

Элек Себер төркиләрендә дә күмү йолаларының бер төре «һавага күмү» була. Себернең салкын, кыш озакка сузылган

яклары өчен бу гадәти күренеш, билгеле. Мәетләрне җиргә күмүдән вакытлыча тыелы тору гадәтен Болгар иленә килгән испан гарәбе әл-Гарнати болай дип язып калдырган: «Анда (Болгарда) суыклар шул дәрәҗәгә җитә ки, кемнеңдер берәрсе үлсә, аны алты ай җирли алмый торалар, чөнки җир тимер кебек ката һәм анда кабер казып булмый. Минем кыш ахырында улым үлде, ә мин аны күмә алмадым. Аны күмәргә мөмкин булганчы, ул минем өемдә өч ай ятты. Мәет таш кебек сакланды». Шулай да болгарларда мәетне «агачка күмү» йоласын борынгы традиция итеп һәм Тәңрегә табыну белән бәйләп карарга кирәк.

Бу ышану татар әкиятләрендә дә бар. Әйтик, «Аучы» әкиятендә болай бәян ителә: «Без, ди, җиргә күммибез, ә зур мичкәгә салып, тимер кыршау кидерәбез һәм агачка асып куябыз, ди».

«Агачка күмү» йоласы элек чуаш һәм мордваларда да булган. Чуашлар кышын үлгән кешене каен агачына элеп куйганнар, яз җиткәч кенә күмгәннәр.

Кайбер Кавказ халыклары, мәсәлән, абхазлар, күренекле кешеләрне, үлгәч, биек агачларга беркетелгән агач тартмаларга салганнар.

Борынгы «агачка күмү» йоласы – биек агач аша Тәңрегә корбан бирү йоласыдыр, күрәсең. Ул кеше җанының шул агач аркылы күккә, Тәңрегә күтәрелүенә, биек һәм зур агачлар буйлап үлгән җаннарның Тәңрегә ирешүенә ышану белән бәйләнгән. Шул ук вакытта ул Тәңрегә, аның гамәлләре кояш, җил, яңгырга корбан да булып саналган. Хәзер дә татар зиратлары яшеллеккә күмелгән. Һәр кабер өстендә, очлары белән чайкалып, – «тәсбих әйтеп», – агач үсеп утыра. Зираттагы агачлар изге санала, аларга тияргә ярамый. Алар аша үлгән кеше җаны Тәңрегә аша. Борынгы төрки язмаларда ук җан ниндидер оча алучы зат кыяфәтендә бирелә. «Җаны очты», «коты очты» гыйбарәләре борынгы төрки язмаларда ничек булса, телебездә бүген дә кулланылышта: алар үлемне яки бик нык куркуны белдерәләр. Габдулла Тукайның «Очты дөнья читлегеннән тартынып күңлем кошы» дигән шигъри юллары да шул турыда сөйли. Болгар каберташ язмаларында җан канатларын җәйгән кош рәвешендә сурәтләнгән. Җанны кош белән чагыштыру күп халыкларда таралган. Мәсәлән, якутлар кабер почмакларындагы таякларга кош рәсемнәре беркеткәннәр.

*Болгар кабер ташында кош кыяфәтендәге җан сурәте*



Борынгылар да бакый дөньяны фани дөньяның күчермәсе кебек күзаллаганнар. Үлгән кеше анда да нәкъ шулай гомер сөрә дип уйлап, ул дөньяны да җирдәге шартлар белән тәэмин итәргә омтылганнар. Алар өчен йортлар «салганнар». Пирамидалар төзегәннәр. Каберләр өстенә ишек, тәрәзәсез биек манаралар корганнар. Мондый бик күп манаралардан торган зиратларны еш кына «үлеләр шәһәре» дип йөртәләр. Үлгән кешеләр борынгыдан ук тормыш иткән әйберләре белән бергә күмелгән: кием-салым, эш кораллары һ.б.



*Ананьино кабер ташы*

Бакый дөнья хакында төрле фикерләр булган. Элегрәк кешеләр анда җаннар бик зәгыйфь яши дип уйлаганнар. Саран гына кояш яктырта, имеш. Мохтаҗлык та юк, рәхәтлек тә. Алга таба карашлар үзгәргән. Мәңгелек рәхәтлек урыны – оҗмах, гөнаһлылар өчен җәза урыны – тәмуг, җәһәннәм хакында фикерләр туган. Алар инде бик борынгы заманнардан ук барлыкка килсәләр дә, дөнья диннәрендә генә оешып җитә алганнар. Шул вакыттан бирле үлем вакытлы дөньядан мәңгелеккә күчү юлы дип бәяләнә башлаган.

Археологиядә Ананьино культурасы дип йөртелгән кабиләләрнең (моннан 1800 еллар элек яшәгәннәр) күмү йолалары да гыйбрәтле. Бу археологик культура беренче тапкыр XIX гасырда хәзерге Алабуга районының Ананьино авылы янында табыла. Алар – фин-угор халыкларының борынгы бабалары. Әмма Ананьино культурасында төркиләр дөньясы белән аваздаш элементлар да шактый. Бәлки, алар, бу якларга килеп, фин-угор кабиләләре тәэсиренә дучар булган төркиләрдер. Башта аларны мөселманнар дип уйлаганнар, чөнки бу җирлектә болгар-татар кабер ташларына охшаган ядкәрләр табылган. Кабер ташларына күмелгән кешенең схематик рәсеме яисә кабилә башлыкларының символларын белдергән хәнҗәр, айбалта сурәтләре уелган. Ананьинолыларның зиратлары үзләре яшәгән җирдән ерак булмаган. Үлгән кешеләрне, һуннар кебек үк, аяклары белән елгага каратып күмә торган булганнар. Күрәсең, елга үлгән кешеләр өчен бакый дөньяга бару юлы итеп каралгандыр. «Үлем елгасы» идеясе һуннар карашында да урын алган. Бу да – Ананьино кабиләләре арасында борынгы төрки катлам булу мөмкинлегенә кечкенә бер өстәмә дәлил. Мәңгелек дөньяга юл озын һәм бик җәфалы дип уйланылган. Шуңа күрә кабергә, корал, бизәнү әйберләреннән тыш, савыт-сабаларга салып, ризык һәм ит куелган. Күчмә төрки халыкларда да үлеләр дөньясына тизрәк барып җитү өчен ат белән бергә күмү йоласы киң таралган. Ир-атны, кайчак хатын-кызны да ат һәм аның кирәк-яраклары белән бергә күмү – болгар күмү йоласының бер характерлы үзенчәлеге. Бу – борынгы төрки күмү йоласының төп сыйфаты. Ат белән бергә күмү йоласы, аермалыклар булса да, салты һәм угыр культурасында да бар. Болгар-Салты ядкәрләренә – ат аягының аскы, Кушнаренко (угыр) культурасына – сул аягының бот өлеше, Танкеевка истәлекләренә атның калак сөяге ите белән күмү хас. Фарсы тарихчысы Рәшидеддин (1247–1318) елъязмаларына караганда, төрки кабиләләрдә бер хайванның, бу очракта атның, аерым өлешләре дә кабилә тотемы, символы була алган. Атның тулы гәүдәсе белән күмү, билгеле, ул чорда да бик кыйммәткә төшкән. Шуңа күрә борынгылар ат гәүдәсенең бер өлеше белән генә күмә башлаганнар: тиресе, башы яисә аягы. Бу – го-

муммифологиядә өлеш аша тулы кыяфәтне күзаллау белән бәйле күренеш. Ул безнең якларга Урал, Көнбатыш Себер якларыннан килеп керә һәм тора-бара хәзәр-болгарларның күмү йоласында иң әһәмиятле күренешкә әверелә. Күчмә халыкларда, шул исәптән һуннар һәм борынгы төркиләрнең күмү йолаларында да бу – киң таралган күренеш. «Тай биреп елаткан, ат биреп туктата алмаган» дигән татар халык мәкале дә шушы борынгы йоланы чагылдыра кебек. Күрәсең, бу атлар, угызлардагы кебек үк, болгарлар уйлавынча, мәңгелек дөньяга, оҗмахка барып җитү өчен кирәк булган. Борынгы төркиләрдә ат Күк белән Җир арадашчысы да булган. Барыннан да элек ул – кеше җаннарын күккә ашыручы. Күк белән Җир арадашчысы, Тәңренең әмерен «җиренә җиткерүче» Юл тәңре вазифасын да алмачуар яки кара ат үтәгән.

Борынгы төркиләр, шул исәптән болгарлар, борынгы бабаларын, аларның рухларын ничек күз алдына китергәннәр соң? Бу җәһәттән Идел буе Болгар җирендә (Биләрдә, Биләр янындагы Балынгуз шәһәрлегендә, Чистай районында һ.б.) табылган бронза «гарип сыннар» бик кызыклы. Алар очлы баш киемнәреннән; еш кына бер куллы, бер аяклы; кайберләренең бер күзе юк. Сыннарда симметрия сакланмаган. Бу аеруча кул, аяклар торышында күзгә ташлана. Алар бик кыска яки гәүдә белән чагыштырганда озын. Кыска беләкләр очлаеп бетә, бармаклар юк яки йодрык урынына бала башы сыннары куелган. Кеше йөзләре кайчак барельеф рәвешендә сыннарның күкрәкләренә дә төшерелгән.



*Бронза «гарип сыннар»*

Шундый ук сыннар борынгы төрки кабиләләр яшәгән җирләрдә дә табылган. Алар төрки кабиләләрнең тотем генеалогия культы белән бәйле. Алтай төркиләре борынгы җир асты алласы Өрликне (Өрклиг) дә шулай күз алдына китергәннәр. Үлгәч җир асты дөньясы затларына әверелгән бабалар да ямьсез, шыксыз кыяфәт алганнар. Аларга күзләр дә кирәк булмаган. Алтай шаманнары бабалар рухларын «күзсез, сукыр» итеп тасвирлаганнар, һәм еш кына аларны «күрмәсләр» дип йөрткәннәр. Татар телендә «көнкүреш», «көн күрү» дигән сүзләр бар. Алар телебездә «тормыш», «яшәеш» сүзләренең синонимнары буларак кулланыла. «Кояш» сүзенең борынгы тамыры – «көн». Аннан «көнеш», ә аннары «кояш» сүзе ясалган. Ягъни «көн» сүзе «кояш» мәгънәсен дә белдергән. Димәк, борынгы заманнардан ук килгән бик мәгънәле «көнкүреш» («кояшны күрү») сүзе – яшәү яисә тормышны, ә кояшны күрмәү үлемне белдергән. Борынгы төрки язмаларда шулай дип язылган да: «Кояш һәм айны сизми башладым» (ягъни «үлдем» мәгънәсендә).

Әйе, һәр борынгы халык, тормыш һәм үлем хакында фикерләп, үзенең кыйммәтләр системасын билгеләгән. Шул рәвешле үлемнең котылгысызлыгын, барыбер киләчәген белә торып тулы канлы тормыш алып бару, рухи тынычлык тудыру өчен образ һәм символлар системасын булдырганнар. Яшәү белән үлемгә кагылышлы гаҗәеп авыр психологик сорауларга борынгы кешеләр беренче җавапларны шулай тапканнар.

**Магия** дә (латин телендә magia «тылсым» мәгънәсен аңлата) – борынгы диннәрнең бер формасы. Ул – чынбарлыкка гайре табигый юллар белән тәэсир итүгә һәм ышануга нигезләнгән карашлар, хәрәкәтләр системасы. Аның чаралары төрле булырга мөмкин: сихер, тылсым, өшкерү, каргыш, аерым йолалар, символлар һ.б. Сәнгать белән дин бер үк вакытта барлыкка килә һәм алар борынгылыкта үзара тыгыз бәйләнештә яшиләр. Бу чор сәнгатендә аучылык һәм уңдырышлылык магияләре өстенлек итә. Шул рәвешле сәнгать ул дәвердә беренче чиратта хозурлану чарасы түгел, ә магик тәэсир итү чарасы булган. Борынгыларның рәсемнәре дә шуңа күрә яшерен урыннарда күбрәк табыла. Нәкый Исәнбәтнең «Зифа» комедиясен генә искә төшерик: Кәләмзә магиянең нинди генә юлларын кулланмый. Монда сихерләү дә, каргау да, символик хәрәкәтләр дә бар. Магик сүзләр нигезендә күп кенә табышмаклар, җор сүзләр барлыкка килгән. Без хә-

*Көньяк Франциянең Монтеспана мәгарәсендәге Аю гыйбадәтханәсе*




зер дә күз тиюгә, каргышларга, сихерләргә ышанабыз. Төрле магик юллар белән проблемаларыбызны җиңел генә хәл итәргә омтылабыз. Алда әйтеп үтелгәнчә, борынгы диннәрнең һәр төре хәзерге диннәрнең нигезендә ята.

Түбәндә моннан 25–30 мең ел элек хәзерге Чехиянең Доли-Вестонице дип аталган җирендә булган йола күренешен китерәбез.

Изге, зур ыру учагы янына ирләр җыелган... Ыру кешеләренең күптән инде юньләп ашаганнары юк. Соңгы вакытта һәр ау уңышсыз тәмамлана. Аларны ач үлем көтә. Кинәт яңа хәбәр ишетелә: бу якларга киекләр килгән. Ирләрнең күзендә өмет уты кабына. Алар иртәгә ауга чыгарга ниятлиләр. Бар да учак янында төрле магик хәрәкәтләр ясаучы, ирләр аңламаган тылсымлы сүзләр пышылдаучы ыру шаманына киеренкелек белән текәлгәннәр. Шаманның җилкәсенә аю тиресе асылган, йөзенә серле рәсемнәр төшерелгән, озын чәчләре май белән сыланган. Йонлы күкрәгендә кызыл түгәрәк тап бар. Кулында балчык белән көл кушып ясалган, кибә башлаган хайван сыннары. Менә Шаман учакка коры-сары сала. Учак дөрләп янып китә. Шаман учак янында хайван хәрәкәтләре ясап йөри, сикерә, кычкыра башлый. Шуннан соң кулындагы хайван сыннарын изә һәм берәм-берәм утка ташлый. «Аудагы барлык киекләргә үлем! Алар без корган яшерен ауларга эләксеннәр; качканда, аяклары аксасын; тәннәренә

*Ау алдыннан*





*Хайван кыяфәтенә кергән шаманнар биюе*

ук, сөңге кадалсын!» Тагын магик хәрәкәтләр ясый. Аннары, аучыларга борылып: «Ауга барыгыз! Минем тылсым сезгә хайваннар ауларга ярдәм итәр», – дип кычкыра.

Күргәнебезчә, магик йолалар белән шаманнар идарә иткән. Алар гадәттә хайван кыяфәтенә кергәннәр, битлекләр кигәннәр. Чәчләрен, битләрен буяганнар. Йола вакытында төрле әйберләрдән файдаланганнар. Болар нигездә шалтырый торган әйберләр булган. Барабаннар какканнар. Бу явыз рухларны куркыту өчен шулай эшләнгән.

### Борынгы медицина

Кешелекне борынгы заманнардан бирле яшәү белән үлем, сау-сәламәт гомер итү, төрле авыруларны булдырмау, авырулардан тиз һәм җиңел котылу юлларын табу мәсьәләләре борчып килә. Иң борынгы диннәр – тотемизм, фетишизм, магия дә борынгы медик карашлар белән тыгыз бәйләнгән булган.

Борынгы кешеләр тотем үзенә табынучы кешеләрне бәла-казалар белән беррәттән авырулардан да саклый, коткара дип ышанганнар. Авырганда, дәва итеп тотем хайванның төрле әгъзаларыннан файдаланганнар; сөтен тамызганнар; йонын яндырып иснәгәннәр; мөгезен кырып, аны су белән болгатып эчкәннәр. Терелү өчен хәтта сулышы да файдалы дип исәпләгәннәр. Билгеле бер хайван, кош-корт (аю, бүре, эт, ат, кондыз, сусар, әтәч, тавык, козгын, бака һ.б.) әгъзаларын файдалану соңгы чор халык медицинасында да киң таралыш алган.

Фетишка әверелгән әйбернең төрле чирләрдән саклау, дәвалау көченә ышанганнар. Аларны саклагыч бөти итеп тагып йөргәннәр. Борынгы кеше авырудан котылу өчен мөмкин һәм мөмкин булмаган бар нәрсәдән дә файдаланган. Аларның күпчелеге файда бирмәгән, әлбәттә. Хәтта кайберләре авыруның хәлен авырайтканнар гына. Әмма алар авыру кеше өчен бик әһәмиятле психологик терәк булганнар, терелүгә ышаныч тудырганнар. Шулай да кеше гасырлар иләген үтеп килгән файдалы дәваларны аерып ала алган. Болар, нигездә, табигатьтә киң таралган минераллар, үсемлекләр һ.б. булган.

Кеше җан һәм тән сихәтенең бер-берсенә бәйлелеген бик борынгы заманнарда ук төшенгән. Борынгы кеше җан белән рухны да материаль хәлдә яши дип күз алдына китергән. Аның фикеренчә, чир дә матди хәлдә яшәгән. Ул аны гадәттә нindидер коточкыч кыяфәттәге җан иясе

рәвешендә күзаллаган. Шул рәвешле чирдән саклану, котылу юлында магиягә, төрле сихерләргә иксез-чиксез мөмкинлекләр туган. Магик хәрәкәтләр, сүз белән кешенең халәтенә, җанына, рухына һәм чиргә тәэсир итәргә омтылганнар. Иң беренче табиблар шаманнар булган. Алар, авыру янында төрле хәрәкәтләр ясап, тылсымлы сүзләр әйтеп, чирне «табарга» һәм кешедән «куып чыгарырга» омтылганнар. Тора-бара рухи тормышта бүленеш барлыкка килгәч, авырулар белән махсус шөгыльләнүчеләр, им-томчылар аерылып чыккан.

Сүз белән чиргә тәэсир итүгә ышану аеруча ырымнарда ачык чагыла. Аларның исемнәреннән үк күренгәнчә, авыруны терелтү өчен, чирнең «телен» белергә кирәк булган. Шуңа күрә ырымнар төрле исемнәр белән аталган: «Зыяндаш (бума авыруы) теле», «Очан (эч авыруы) теле», «Эт имчәге теле» һ.б. Менә шулардан кайберләре:



*Борынгы төрки шаман. Заһир Хәкимов рәсеме*

**«БИЗГӘК» ЫРЫМЫ**

Ак атка атланып куармын,
Кара атка атланып куармын,
Күк атка атланып куармын,
Ала атка атланып куармын.
Тимер көрәк белән кырырмын,
Тырма белән тырнармын,
Тимер себерке белән
себерермен.
Кырдым, тырнадым, себердем.

**«ЧИР КУУ» ЫРЫМЫ**

Бас, бассала, басыгралла,
Баз өстендә басыгралла.
Басма түшәкләр өстендә
Шайтан белән кысыгралла.
Озын койрык саесканның
Койрык очын чыбыгралла.
Качып киткән шайтаннарны
Юкә күлдән табыгралла.
Җирән атым җилшералла,
Җилеп тауга меншералла.
Әлеге шайтан килшералла,
Яулык тулы имшералла.

Әлеге ырымнарда «җанлы» чирне куркыталар, аңа яныйлар. Зәхмәтне аерым сүзләрне бик ямьсез итеп әйтеп тә куркыталар. Ырымнардагы кайбер сүзләрнең мәгънәләрен дә аңлавы авыр. Бу – имченең теләген чир аңламасын өчен шулай махсус эшләнгән булса кирәк. Аңлашылмаган нәрсә һәрчак серле дә, куркыныч та бит ул. Борынгылар чир авыру кешенең эченә кеше яки хайван кыяфәтендә азык-төлек белән яки зарарлы җил аша керә дип уйлаганнар. Шуның өчен дә азык-төлек салган савытны саклау аеруча әһәмиятле булган. Күп кенә бо-

рынгы кабиләләр, шул исәптән болгарлар да савыт-саба тоткаларын теге яки бу хайван кыяфәтендә (поши, ат, аю һ.б.) ясаганнар. Шул рәвешле алар савыттагы ризыкны явыз көчләр, авырулар тәэсиреннән саклыйлар дип ышанганнар. Савытларның өсләрен ябып, сихерле сүзләр әйткәннәр. Ислам дине таралгач, бу сүзләрне «бисмилла» алмаштырган. Им-томчының максаты, чир кереп урнашкан («яшеренгән») җирне табып, аны буу, «йозаклау» булган.

Кешене дәвалаучылар гына түгел, «бозучылар» да булган. Моның өчен дә төрле ырымнар эшкә җигелгән. Бу максаттан кешенең коелган чәче, киселгән тырнагы, ашаласы ризыгы һ.б. файдаланылган.

Димәк, диннәр тарихына күз салсак, иң борынгы аллалар хайван яисә кош-корт кыяфәтендә булган. Кеше кыяфәтендәге аллалар барлыкка килгәнче, озын юл үтелгән. Схематик рәвештә аны болай күз алдына китерергә булыр иде: хайван алла → хайван һәм кеше алла синтезы (күчмә чорда) → кеше кыяфәтендәге алла. Алга таба да үзгәреш дәвам итә. Иң югары үсешкә ирешкән диннәрдә Алла кемгәдер яисә нәрсәгәдер охшатып күзалланмый. Ул бөек илаһият, изге рух булып тасмерләнә. Бу юнәлештә барыннан да бигрәк ислам дине үсеш-үзгәреш кичерә.



*Кошка охшаган пот. Бронза. IX–XI гасырлар*

Хайван алладан кеше кыяфәтендәге аллага күчеш идеясе Урта Идел һәм Кама буйларындагы борынгы угор телле кабиләләр сәнгатендә дә күренә (я.э. (б.э.) кадәр II – я.э. V гасырлары – пьянобор культурасы, ломоватово культурасы). Аларда аеруча кеше һәм кош сыйфатларының кушылуы күзәтелә. Канатларын җәйгән бер яки берничә башлы кош күкрәгендә кеше башы, кеше йөзе яисә кеше сыны сурәтләнгән.

Соңрак сурәтләрдә кеше хасиятләре өстенлек итә. Әмма боларның да башы – кошка, йөзе кешегә охшаган, канатлары да бар. Билгеле, алар тагын да борынгырак идеяләрне чагылдырырга мөмкин. Бу – кеше белән табигатьнең аерылгысыз бергәлеге, табигать күренешләре белән кешенең үзара әверелеш мөмкинлегенә ышану.

Әле аллалар кешеләшкәч тә (бу, беренче кешелек җәмгыяте таркалып, сыйнфый җәмгыятьләр оешкан вакытта була), тиз генә хайван сыйфатларыннан котыла алмаганнар. Мәсәлән, борынгы Мисырда Кояш алласы Гар – лачын, Ай алласы – ибис (җылы якларда яшәүче ләкләккә охшаган кош) башлы. Борынгы Грециядә акыллылык һәм хак сугыш алласы Афина Паллада ябалак күзле булган. Зевста – бүре, аның хатыны Герада тутый кош сыйфатлары сакланган.

## СӘНГАТЬ


Без алдагы бүлекләрдә борынгы кешенең табигать белән берлеген, дөньяга карашын, борынгылыкта аларның рухи чагылышын карап үттек. Шундый кыйммәтләрнең тагын бер иң көчле чагылышы – сынлы сәнгать. Галимнәр фикеренчә, кеше 2 миллион еллар чамасы элек барлыкка килсә дә, археологик табышларга караганда, дин һәм сәнгатьнең төрле өлкәләре бик соң, моннан 30–40 мең еллар чамасы элек туа. Бу – югары палеолит чоры. Бу чор кешесе үзенең биологик сыйфатлары белән хәзерге кешедән нигездә аерылмаган. Сөйләшә алган. Ырулык оешмасын яхшы белгән. (Ырулык оешмасы ике өлештән торган. Аның һәрберсенең эчендә никах мөнәсәбәтләре тыелган.) Таштан, сөяк, мөгезләрдән кораллар ясалган. Дини карашлары формалашкан. Әкренләп иң борынгы бабабыз кешеләшкән. Баш мие, күрүе, ишетүе, бармаклары әйләнә-тирәдәге матурлыкны, тормыш-көнкүрешне тоя белерлек дәрәҗәдә камилләшкән. Кешеләшү процессы бик озак барган. Димәк, кешелек тарихында бик озак динсез, сәнгатьсез чор да булган әле. Хәер, дине, сәнгате булмаса, кешелекне чын кешелек дип әйтеп тә булмый торгандыр.

Беренче кешеләрнең яшәү урыннарын казып тикшергәндә, алардан калган археологик истәлекләр арасында чакматаштан эшләнгән кораллардан һәм хайван сөякләреннән башка берни калмаган кебек булса да, эш кораллары үсешен күзәтү бик кызык нәтиҗәләргә китерә. Әкренләп бу чуерташ кораллар шундый камиллеккә, уңайлылыкка ирешәләр ки, чыннан да борынгы кеше ташның бар мөмкинлегеннән файдаланып бетергән кебек тоела. Коралларны тагын да камилләштерү алга таба бары тик башка материал – тимер куллану җирлегендә генә мөмкин була. Шулай итеп таш кораллар сәнгать югарылыгы дәрәҗәсенә җитә. Әмма әле бу сәнгатьнең үзе булмый.

Таш гасырының урталарында (мезолит), моннан 7–10 мең еллар чамасы элек ук һәм җәя уйлап табыла. Бу җитештерү көчләре үсешендә чын мәгънәсендә зур сикереш була һәм таш гасырының беренче примитив техникасы санала. Моны хәзерге атом төзелешен ачу, космик киңлекләрне үзләштерү кебек зур ачышларга тиңләргә мөмкин. Җәя уйлап табып, кеше беренче тапкыр кинетик көчтән файдаланган. Кешегә очып баручы кошларны, кеше аягы баса алмаслык урыннардан киртәләр аша һәм ерактан торып хайваннарны аулый алу мөмкинлеге туган. Бу гамәли яктан шулай. Ук, җәя уйлап табу беренче кешелек культурасы һәм сәнгате үсешенә дә уңай тәэсир ясаган. Җәядән ату кул

*Яңа таш гасыры (неолит) кораллары*








*Урта таш гасырында (мезолит) болан аулау күренешләре*

һәм бармакларның төгәллеген, житезлеген, күзләрнең үткерлеген таләп иткән. Кешеераклыкны, күләмне, проекцияне төгәлрәк сиземләргә өйрәнгән. Ук һәм җәягә ия булгач, борынгы кеше үзенең карашын очып баручы кошларга, зәңгәр күккә ешрак төбәгән. Ә иксез-чиксез күк кеше өчен гомер-гомергә хыял, фантазияләр дөньясы булган.

Урта таш гасыры рәссамы күп фигуралы композицияләр ясаган. Аларда ау, хайваннарны эзәрлекләү, эләктерү өчен уңайлы урынга куып кертү, бал җыю, бию күренешләре хәрәкәттә тасвирланган. Борынгы таш гасырының катып калган сәнгате урынына хәрәкәтле сәнгать барлыкка килгән. Хайваннар урынына кеше рәсемнәре үзәк урынны алган. Ләкин аларның рәсемнәре бик шартлы рәвештә генә ясалган.

Билгеле, бер үк вакытта диярлек барлыкка килгән дин дә, сәнгать тә әзер килеш тумаганнар. Бүгенге көн дәрәҗәсенә җитү өчен, алар күп гасырлардан торган озын юл үткәннәр. Дин һәм сәнгать кеше аңының, гомумән, беренче кешелек җәмгыяте рухи тормышының үзенчәлеге белән тыгыз бәйләнгән. Борынгы кешегә үзе яшәгән ырулык җәмгыяте мөнәсәбәтләре генә якын һәм аңлаешлы булган. Шуңа күрә ул табигатьне шушы мөнәсәбәтләргә күчереп танып белгән. Аның өчен әйләнәтирә дөнья үзе үк бербөтен зур ыру булган. Кеше табигатьне, үзен әйләндереп алган дөньяны бары тик ыру эчендә урнашкан мөнәсәбәтләр аша гына бәяли алган. Ырулык җәмгыятенең үзендә бернинди серле һәм гайре табигый нәрсә булмаган. Әмма табигый булмаган шул мөнәсәбәтләрне табигатькә күчерү белән бар табигать кеше аңында кинәт мифик һәм магик характер алган, җан ияләре белән тулган.




*Палеолитның соңгы чорында кисеп ясалган хайван сыннары күп очрый. Бу гаҗәп түгел, чөнки бу чор кешеләре беренче чиратта сунарчылык белән көн күргәннәр. Иң элек үзләре аулаган хайван сыннарын ясаганнар. Барыннан да элек мамонтлар, төньяк пошилары, кыргый атлар, үгезләр, бизоннар, сирәгрәк кыргый кабаннар, боланнар, кәҗәләр, соры аюлар. Ерткыч хайван сыннары бик сирәк очрый.*

*Үзбәкстандагы Тишек Таш мәгарәсе аучыларының тау кәҗәләрен (киекләрен) аулау күренеше. Бер төркем кешеләр кәҗәләрне текә кыя кырыена куып китерәләр. Тарлавыкны бик сирәк кәҗәләр генә сикереп чыга ала. Калганнары тарлавык астында аларның егылып төшүен көткән кешеләр кулына эләгә*



Сыннарны башта мамонт тешләреннән, болан мөгезләреннән ясаганнар.

Хайван сөягендә, мәгарә диварларында да хайван рәсемнәре, ау күренешләре тасвирланган. Бу аңлашыла да, чөнки борынгы кеше тормышында хайваннар искиткеч әһәмиятле урын тоткан. Бер төр хайваннар аның өчен азык-төлек, кием-салым, төрле көнкүреш әйберләрен ясау чыганагы булса (сөягеннән кораллар, бизәнү әйберләре, бөтиләр һ.б. эшләнгән), икенчеләре дәһшәт тудырган. Шуңа күрә дә аларның беренче аллалары хайваннар булган. Һәркайда төрле, әмма зур хайваннар сурәте ясалган. Бу да аңлашыла, чөнки куян ише хайван белән генә тулы бер ыруны туйдырып булмый. Вак хайваннарны куып җитәргә яисә ауларга да авыр. Зур хайваннарны тозакка эләктерүе җиңелрәк. Бу вакытта



*Борынгы рәссам тылсым тудыра*

әле эт, ат кебек хайваннар кулга ияләштерелмәгән.

Шулай итеп борынгы таш гасырында – палеолитта – сәнгать барлыкка килә. Аның иң күренекле ядкәрләре Көнбатыш Европа мәгарәләрендә саклана. Болан, зубр, мамонт, кыргый ат рәсемнәре мәгарә диварлары яисә түшәмнәрендә катып калган. Бу – таш гасырының искитмәле картиналар галереясе. Андагы рәсемнәр табигый буяулар белән ясалган. Борынгы рәссам аеруча табигый кызыл буяу – охра белән ясарга яраткан. Ут ярдәмендә табигый охраның сары төстән куе кызылга кадәр геләреннән файдаланган. Нигездә рәсемнең контурына кара төс бирү өчен табигый марганец яки учак күмереннән файдаланган. Рәссамның бер кулында охрага манчылган пумала булса, икенчесенә кисәү тоткан. Ул, кан төсен кулланып, үз рәсемнәренә җан өрергә, тормыш көче бирергә омтылган. Борынгы рәссам кан белән җанның тыгыз бәйләнештә булуын бик яхшы аңлаган. Ау вакытында яраланган хайваннан кан агуын күргән. Хайван тәненнән кан белән бергә җан да киткән. Рәсемнәрдәге хайваннар шулкадәр табигый итеп сурәтләнгән, аларны киң далаларда яисә урманнарда үлән ашап яисә чабып йөрүче хайваннардан аерып та булмаган.

Димәк, беренчел сәнгатькә самими реализм, натурализм хас. Хайван сурәтләрендәге гаҗәеп тормышчанлык бу чор кешесенең аучылык тәҗрибәсе, ау вакытында хайваннарны күзәтү, өйрәнү нәтиҗәсендә туган.

Борынгы рәссам табигатьтә хайван нинди зурлыкта булса, рәсемдә дә шушы зурлыкны сакларга омтылган. Бу – иҗат методы дигән төшенчәдән ерак күренеш, әлбәттә. Әмма борынгы кеше башкача булдыра да алмаган, чөнки аның фикерләве бөтенләй үзгә булган. Ул масштаб дигән берәмлекне белмәгән. Рәсем сәнгатендәге проекция закончалыгын да аңламаган. Ерактагы һәм якындагы күренешләрне дә бер зурлыкта ясаган. Шулай да инде бу чорда ук сәнгатьне сәнгать иткән принципларны күреп була. Ау һәм хезмәт эшчәнлеге күренешләрен аерып алып мәгарә диварларына төшерү чынбарлыкны гомумиләштерүгә юл ача. Ә бу – сәнгатьнең иң әһәмиятле принцибы.

Беренчел сәнгатьтә кешеләрнең әйләнә-тирә дөнья хакында тәүге карашлары чагылган, үзара аралашу мөмкинлекләре арткан. Сәнгать ярдәмендә борынгы кешеләр үзләренең белемнәрен, күнекмәләрен саклап калганнар. Шулай итеп, сәнгать борынгы кешеләр тормышында күпкырлы роль уйнаган.

Рәсем ясау изге эш саналган. Рәссам үзе тылсым иясе булып, рәсемнәрдәге хайваннар тере кебек тоелганнар. Борынгы кешеләр, рәсемнәр янында төрле йолалар үткәреп, ауда уңышка ирешергә омтылганнар. Рәсемдәге хайван битлекләрен киеп (янәсе, битлек кигән аучыны хайваннар танымый), кулларына сөңгеләр тотып, төрле каргышлар кычкырып, йола биюләре башкарганнар. Аннары сөңгеләре белән рәсемдәге хайваннарны «үтергәннәр». Мондый йола яшәр өчен әһәмияте зур булган җитди эш – ау алдыннан үзенә күрә бер «генераль репетиция» кебек булган.

...Мәгарә эчендә зур ыру учагы яна. Үз зурлыгындагы хайван рәсемнәре төшерелгән диварларда, түшәмнәрдә учак шәүләсе уйный. Шуңа күрә рәсемдәге хайваннар хәрәкәт итә: йөгерә, кешегә ташлана сыман тоела. Ыруның барлык кешеләре дә барабан һ.б. төрле тавышлар астында ритуаль бию башкара. Әйтерсең бар да буталган: кешеләр дә, рәсемдәге хайваннар да, чынбарлык та, фантастик дөнья да. Бу кадәр тырышкач, ау уңышлы булачак, ыру исән калачак дип уйлаганнар борынгы кешеләр. Мәгарә алар өчен гыйбадәтханә вазифасын да үтәгән. Кеше шул рәвешле үзе дә аңламыйча сәнгатькә табынган... Монда уздырылган йолаларда киләчәктә туачак җырларның да, бию, шигырь, театрның да беренче яралгылары туган. Кешенең ауланачак хайванга охшатып бизәнүе (буяулар белән грим салуы һ.б.), битлек, өстенә хайван тиресе киюе, хайванга охшаш хәрәкәтләр ясап кылануы, биюе аны чын драма артистына әверелдергән.

Бозлык чоры беренче кешеләрне мәгарәләргә куып керткән. Беренче тапкыр борынгы таш гасырына (палеолит, я.э.к. 35–10 меңьеллыклар) караган рәсемнәр Пирәнәй ярымутравында, Испаниянең төньягындагы Альтамира мәгарәсендә табыла. Һәвәскәр тарихчы Марселино де Саутуола 1879 елда 7 яшьлек кызы Мария белән үз ихатасыннан ерак түгел Альтамира мәгарәсенә керә һәм хайван сөякләреннән, мөгезләреннән, таштан ясалган эш кораллары, сөңге очлары, сөяк энәләр, кабырчыклардан эшләнгән бизәнү әйберләре таба. Дивар һәм түшәмнәрдәге рәсемнәрне күреп, алар таң калалар. Сурәтләр шулкадәр чын кебек була, хайваннар, дивар һәм түшәмнәрдән төшеп, мәгарәдән чыгарлар да далага таралырлар кебек тоела. Рәсемнәр арасында яраланган бизон бигрәк тә табигый сурәтлән-



*Испаниянең Альтамира мәгарәсендәге бизон рәсеме*



*Франциянең Фон-де-Гом мәгарәсендәге болан рәсеме*

гән. Борынгы кешеләрне үтә кыргый дип санаган һәм аларга үз югарылыгыннан торып, масаеп караган Европа кешеләре галимнең ачышына ышанмыйлар. Тарихчы бу рәсемнәрнең табигать тарафыннан очраклы рәвештә генә ясалган бизәкләр яки галим фантазиясе белән генә тудырылган рәсемнәр булмавын гомер буе исбатларга мәҗбүр була.

1940 елның сентябрь аенда өлкән сыйныф укучылары Франциянең көньяк-көнбатышында көчле җил белән каерып атылган агач төбендә тишек табалар. Алар моны борынгы замокка алып бара торган җир асты тишеге дип уйлыйлар. Бер укучы тишеккә таш атып карый. Тишекнең шактый тирән булуы ачыклана. Батыррак бер укучы, маҗара эзләп, тишекне киңәйтә дә төшеп китә. Фонаре белән яктырткач, ах итә. Башкаларны да үз янына чакыра. Укучылар мәгарә диварларында зур, көчле, ярсып ташланырга торган сыман ерткыч сурәтләрен күрәләр һәм куркып калалар. Бу рәсемнәр шулкадәр чын, мәһабәт була, балалар үзләрен серле патшалыкка эләккән кебек хис итәләр. Бу турыда укытучыларына сөйлиләр. Әлеге хәбәргә ышанмаган укытучы үзе дә мәгарәгә төшә һәм рәсемнәрне күреп гаҗәпләнә. Хәбәр тиз арада тирә-юньгә дә тарала. Мәгарәгә халык агыла башлый. Хәтта мәгарә рәсемнәренә куркыныч туа. Укучылар, аның янында чатырлар корып, мәгарәне саклый башлыйлар.

Ласко мәгарәсендә (мәгарәне шул исем белән атыйлар) табылган әлеге рәсемнәр галереясен беренчел көнкүрешнең «Сикстин капелласы» дип тә йөртәләр. Ул я.э.к. XVIII меңьеллыкка карый. Франциядә палеолит чорына караган Фон-де-Гом мәгарәсендәге зур, мәһабәт мөгезле утлап йөрүче болан рәсеме дә гаҗәп табигый ясалган.

Озак еллар буе Көнбатыш Европа (аеруча Испания, Франция) рәсемле мәгарәләр сакланган бердәнбер урын дип уйланыла иде. Соңгы елларда безнең якларда да беренче кешелек җәмгыяте тудырган сәнгать әсәрләре табылды. Шундый гаҗәеп мәгарәләрдән мисалга Башкортстанның Бөрҗән районындагы Шүлгәнташ (русча Каповая яки Капова пещера) мәгарәсен китерергә мөмкин.

1959 елда зоолог Александр Рюмин бу мәгарәгә ярканатлар эзләп төшә һәм беренче кешелек җәмгыятенең картиналар галереясенә юлыга. Аннары бу мәгарә, андагы рәсемнәр һәм таш гасыры кешеләреннән калган таш кораллар академик Отто Бадер җитәкчелегендәге археологлар һәм соңрак Франция, Германия галимнәре тарафыннан өйрәнелә. Мәгарә ишеге бик зур: иңе 40 метр, биеклеге 22 метрлы ар-

ка формасында була. Анда 2250 метр озынлыгындагы җир асты юллары, 9 зал бар. Мәгарә 3 катлы. Беренче катында Шүлгән исемле җир асты елгасы ага, ике күл бар. Берсе Европада иң зур җир асты күле санала. Аның диаметры 400 метр. Икенче катка күтәрелү өчен борынгы кешеләр 14 метр тирәнлектәге кое аша үтәргә тиеш булганнар. Бу вертикаль юл урта катка алып менә. Анда зур заллар урнашкан. Соңгы югары кат Агыйдел елгасыннан 40 метр биеклектә. Монда түбәнгә ыргылучы шарлавыклар шаулый. Бу мәгарәгә 1 миллион елдан артык.

Мәгарә диварларындагы рәсемнәр хайван маенда эретелгән кызыл охра белән төшерелгән. Моннан 20 мең ел элек ясалган бу рәсемнәрнең шактые су белән юылган. 16 хайван рәсеме сакланган: 8 мамонт, 4 кыргый ат, 1 йонлач мөгезборын, 1 бизон, 1 мәгарә аюы, 1 кылыч тешле юлбарыс рәсеме. Алар барысы да зур осталык белән ясалган. Шүлгәнташ мәгарәсендәге сурәтләр Көнбатыш Европа, аеруча Ласко мәгарәсендәге рәсемнәргә бик охшаш. Алар гаҗәп табигыйләр, хайваннарның үз-үзләрен тотышларындагы һәм кыяфәтләрендәге үзенчәлекләр бик төгәл бирелгән. Рәсемнәр шул ук вакытта бик гадиләр һәм самимиләр. Хайваннар тыныч кына утлап йөриләр.

Әлеге мәгарәгә килеп эләккән хәзерге заман кешесе үзен монда яхшы хис итә, космос белән бәйләнешен ныграк тоя башлый. Мондагы су,

*Шүлгәнташ мәгарәсенә керә торган урын*




һава, үзле балчык та кешеләргә шифа бирә. Җирле халык мәгарәдә җеннәр, дию пәриләре яшеренгән дип уйлый. Әкиятләрне искә төшерик әле: дию пәрие патша кызын, урлап, җир тишеге аша үз патшалыгына – җир астына алып төшеп китә. Моннан тыш тирә-юньдәге кешеләр анда таш эт бар дип сөйлиләр. Аңа яңгыр болытлары буйсынган, диләр. Таш эткә 100 мәртәбә чыбыркы белән суксаң, тирә-якта бик көчле яңгыр ява башлый, имеш. Шул рәвешле җирле халыкта хәзер дә бу мәгарә хакында күп кенә легендалар йөри.

Алда әйткәнебезчә, баштагы чорда (30 мең еллар элек) борынгы рәссамнар хайваннарның контурын ясап, аларны кара яки кызыл буяу белән буйыйлар. Соңрак (я.э.к. 18–15 меңьеллыкларда) сурәтләнүче хайваннарның аерым детальләренә игътибар итә башлыйлар. Рәсемнәрдә кыек параллель сызыклар белән хайванның йонын, тиресен дә бирергә омтылалар. Төсләрнең төрле төсмерләрен табуга ирешәләр. Үгез, ат, бизон тиреләрен таплар белән, алмачуар итеп сурәтләргә өйрәнәләр. Хайван тиресенең тартылып, җыелып тору рәвешен дә күрсәтәләр, ат, бизоннарның ялларын ясыйлар.

*Шүлгәнташ мәгарәсе рәсемнәре*





Әмма борынгы рәссамнар сәнгатьчә перспективада ясый белмәгәннәр. Хайваннарны һәрвакыт башлары белән кешегә карап тора торган итеп кенә ясаганнар. Кешелек бик озак еллар шундый рәсемнәр белән генә чикләнгән әле. Хәтта күпкә соңрак болгар рәсемнәренең дә шактыйларында хайваннар шул рәвешле бирелгән. Борынгы рәсемнәрдә пропорция, күләм кануннары да сакланмаган. Традиция буларак, бу төр сәнгать – ау объекты булган хайваннарны гына сурәтләү – туып килүче беренчел хайван культы, ау магиясе, сихер белән тыгыз бәйләнештә булган. Табигать кешеләштерелгән мифологик образларда сурәтләнгән, аларга кеше сыйфатлары бирелгән. Борынгы кеше сәнгатьне шулай аңлаган.

Соңгы таш гасыры сәнгате әсәрләренең иң зур күпчелеге уңдырышлылык культы, аучылык йолалары белән бәйле.

Әлеге дәвер рәсемнәрендә тормышчанлык никадәр бөркелеп торса да, бу әле сәнгатьнең бала чагы, чишмә башы гына булган. Борынгы рәссам гомумиләштерүне, пространствоны тоя белмәгән, композицияне бирә алмаган.

Ә инде я.э.к. 12 меңьеллыкта мәгарә

сәнгате зур үсешкә ирешә. Рәссамнар сурәтләрнең зурлыгын, сыннарның пропорцияләрен, хәрәкәтләрен бик табигый бирә ала башлыйлар.

Гомумән, борынгы кешелек җәмгыяте чорында Җир шарының төрле почмакларында таралган сәнгать әсәрләре бик охшаш булган. Кайда гына яшәсә дә, кешенең бер үк үсеш дәрәҗәсе, әйләнә-тирә дөньяны бертөсле тоюы, хыял-омтылыш һәм куркуларындагы охшашлык, хәтта бертөрлелек асылда бер үк төсле рәсемнәр тууга китергән.

Мәгарә яшәү урыны гына түгел, гыйбадәтханә, сәнгать мастерское да булган, дидек. Кешелек үзенең беренче туган, яшәгән йортын бик озак оныта алмаган әле. «Мәгарә сюжеты» төркиләр рухи дөньясында – бабаларыбыз рухи мәдәниятендә дә сизелерлек урын тоткан. Борынгы төркиләр дә һәр елны «бабалар мәгарәсендә» әрвахлар хөрмәтенә корбан китергәннәр, дога кылганнар. Ул соңрак та онытылмаган. Хәтта кайбер чыганаклар болгарларны да «мәгарә кешеләре» дип атыйлар. Соңрак аерым үзгәрешләр белән «мәгарә сюжеты» Казан шәһәре салынасы урынны еланнардан чистарту хакындагы легендада да урын алган.

*Вестонице (Чехия) Венерасы. Хайван сөяге көлен, маен, балчык кушып ясалган измәдән эшләнгән. Сын, учакта яндырылгач, таштан да каты була*



Әкренләп кешеләр көтүе беренчел көнкүреш җәмгыятенә әверелә. Соңгы палеолит чорында кеше үз-үзен расларга, үз-үзенә ышаныч булдырырга омтыла. Я.э.к. 25 меңьеллык – мадлен чоры – борынгы сәнгатьнең иң нык чәчәк аткан чоры була.

Алда язылганча, үлем кешеләрне бик иртә кырган. Шуңа күрә ыруны дәвам иттерү кешенең иң зарури бурычы саналган. Бу максат сәнгатьтә дә чагылыш тапкан.

Беркадәр соңрак – матриархат чорында – сәнгатьтә кеше сыннары да барлыкка килә. Матриархат чорында хатын-кыз тормышта гаять әһәмиятле роль алып торган. Ирләр генә йөргән аучылык күпсанлы кан кардәштән торган ыруны ачлыктан һәм үлемнән һәрчак коткарып кала алмаган. Җыючылык чоры башланган. Кешелекнең төп хезмәте табигатьтәге әзер әйберләрне җыю булган. Үләннәр, аларның тамырлары, җиләк-җимеш, чикләвек һ.б. үсемлекләр кешеләрнең ышанычлы азык-төлек чыганагына әйләнгән. Мондый эшләрне хатын-кызлар аеруча



*Виллендорф (Австрия) Венерасы. Я.э.к. 30–25 мең ел элек*

оста башкарган. Хәзерге чор хатын-кызлары да табигать җимешләрен җыярга бик хирыс. Шул рәвешле бу чорда ана ыруы хакимлек иткән, ыру тормышының башында хатын-кыз торган. Туганлык ана нәселе буенча билгеләнгән. Хаким ана ыруның иминлеген, туктаусыз үсешен тәэмин иткән. Ул ыру учагының сакчысы да булган. Ыру учагының сүнүе ыруның үзенең дә юкка чыгуын аңлаткан.

Шуңа күрә дә беренче кеше рәсемнәренең барысы да хатын-кыз сыннары була. Иң беренче булып төрле илләрдә 150 ләп хатын-кыз сыны табыла. Мондый сыннар сирәк булса да безнең җирле археологик материаллар арасында да очрый. Аларның җенси әгъзалары күпертеп сурәтләнгән. Кешенең йөзе бирелми диярлек. Борынгы кешене хатын-кызның йөз матурлыгы кызыксындырмаган. Хатын-кыз матурлыгын алар ассызыкланган җенси әгъзаларда, нык мускуллы таза гәүдәдә, зур күкрәкләрдә күргәннәр. Рәсемнәргә тагын бер үзенчәлек хас. Алар – бар да көмәнле хатын сыннары.

Ләкин бу сыннар эротикага карамый. Алар – борынгы кешеләрнең матур хатын-кыз идеалы. Бу сыннар борынгы җыючылык эше бик зур әһәмияткә ия булган җәмгыятьтә хатын-кыз һәм аның хезмәтенең урынын күрсәтә торган чорны чагылдыра. Кешелек табигатьтән аерылгысыз. Хатын-кызга өстенлекне табигать биргән. Ул – кеше тудыручы, кешелекне дәвам иттерүче, саклап калучы. Хатын-кыз – уңдырышлылык символы. Борынгы скульптор рәсем-сыннарында шушы идеяләрне бирергә теләгән. Димәк, сыннардан күренгәнчә, хатын-кызның матурлыгы беренче чиратта ана булуда икәнлеген борынгы кешеләр дә бик яхшы аңлаган.

Матриархат чоры кешелек тарихында әһәмиятле урын тота. Ул борынгы төрки чорларга караган сәнгатьтә дә, амазонкалар – сугышчан хатын-кызлар турындагы легендаларда да киң яктыртыла. Амазонкалар – кешелек тарихында иң кызыклы күренешләрнең берсе. Алар яшәгән мәмләкәтләр, шәһәрләр, кешелекнең таң вакытында күргән төшләре кебек, бик күптән юкка чыккан. Әмма алар хәзер дә кешеләрне уйландыра, сокландыра, дулкынландыра. Нәрсә бу? Амазонкалар чынлап та булганмы? Әллә бу матур әкият кенәме? Әллә борынгы греклар тудырган мифлармы? Юк. Бу – реаль тарих белән хыялый дөньяның гаҗәеп матур үрелеше. Алар хакында мифологик легендалар борынгы грекларга кадәр үк барлыкка килгән. Беренче чиратта бу легендаларны Крит утравы цивилизациясе белән бәйләп карыйлар. Соңрак Борынгы Греция тарихчылары амазонкалар Кавказ, Азов буе, Кече Азия, скиф, сармат, алан җирләрендә яшәгәннәр дип язып калдырганнар. Алар турындагы легендалар тора-бара бөтен Евразиядә, шул исәптән төрки дөньяда да тарала. Амазонкалар, бер ир-ат җенесен дә

кертмичә, үзләре генә аерым кальга-шәһәрләрдә яшәгәннәр. Хәтта аерым дәүләтләрнең хуҗалары булу дәрәҗәсенә ирешкәннәр. Нәселләрен дәвам иттерү өчен елга бер тапкыр чит ил йә ят ыру ирләре белән мөнәсәбәткә кергәннәр. Яисә бу максатта әсирлеккә төшкән ирләрне файдаланганнар. Ир бала туса, йә этисенә биреп җибәргәннәр, йә үтергәннәр. Ә кыз бала туса, үзләренчә тәрбияләп үстергәннәр. Җәя тартканда комачауламасын өчен, яңа туган кыз баланың сул күкрәге үсмәслек итеп, шул урынга кызган тимер басканнар.


Алар ук-җәя, сөңге, кылыч, балта, калкан һ.б. коралларны үзләре ясаганнар. Яшьтән үк кыю, батыр, көчле, түземле булып үскәннәр. Атка атланып, ир-атлар гаскәренә каршы бик оста сугышканнар. Ир-ат гаскәрләренең амазонкаларны җиңүе сирәк күренеш һәм зур батырлык булып саналган. Гераклның 12 батырлыгының берсе – тугызынчысы – амазонкаларны җиңү була. Хәтта мәшһүр Александр Македонский гаскәре дә аларны бик зур авырлык белән генә җиңә.

Алга таба мәгарә рәсемнәре үзләренең «терелеген», күләмлелеген югалта, стильләшү, схемалылык көчәя, реализм, табигыйлек юкка чыга.

Таш гасырының ахырында, неолит чорында (яңа таш гасыры)

*Амазонкалар һөҗүме. Борис Валеджо картинасыннан репродукция*





*Грекларның амазонкалар белән сугышы төшерелгән савыт. Я.э.к. 410–400 еллар*

рәсемнәр галереясе бар төбәктә, аеруча елга, күлләрнең көньякка карап торган текә ташлы ярларында күзгә ташлана. Аларны фәндә петроглифлар дип йөртәләр. Болар инде – сюжетлы рәсемнәр. Боларда аеруча төньяк урман аучылары һәм балык тотучыларның тормышы яктыртылган. Алар ярдәмендә рәссам борынгы кеше яисә ыруның барлыкка килүе, бабалары, галәм төзелеше хакында уйлана. Рәсемнәрдә шулай ук хайваннарның үрчүе, аларны аулау күренешләре дә сурәтләнгән. Аучылык үзе дә кешене камилләштергән, аларга берләшү, иҗади эшчәнлекләрен арттыру мөмкинлеге биргән. Кеше үзенең хәйләкәрлеге, зирәклеге белән хайваннардан өстенлеген аңлаган. Рәсемле кыялар яңа таш гасыры кабиләләренең гыйбадәт урыны да булган.

Гасырлар уза тора. Кулдан ясалган беренче өйләр барлыкка килә. Кешеләр аучылыктан игенчелеккә, мал асраучылыкка күчәләр, яңа төр әйберләр ясарга өйрәнәләр. Шулай да рәсемнәр коллектив сәнгать җимеше булып кала. Кешеләр әкренләп рәсемнәрне кечерәйтеп тә ясый башлыйлар. Колоритлы чынбарлыкка нигезләнгән мамонт аулаучыларның мәгарә сәнгате урынына шартлы, символик бизәк-рәсемнәр алмашка килә. Алар белән таш кыялар, кораллар, савыт-саба, кием-салым да бизәлә башлый. Бу – борынгы кешенең абстракт фикер йөртүдә зур уңышка ирешүен күрсәтә торган дәлил. Рәсемнәр гади генә булмаган. Алардагы һәр сызык нәрсәнеңдер символын, нәрсәнедер аңлаткан: түгәрәк – кояш; дулкынлы сызык – елга, диңгез; киртләч сызык – тау; әйләнә яки квадрат эчендәге нокта – чәчелгән басу һ.б. Болар язуның беренче «бабалары» булганнар. Әмма чын язу барлыкка килгәнче бик озак вакытлар кирәк булган әле.

Орнаментның чын мәгънәсендә чәчәк ату чоры неолит, бронза чорына карый, һәм бу кешеләр тормышында зур ачыш ясалган чүлмәк савыт-саба ясый башлау белән бәйле. Савытның түгәрәк формасы, шома өслеге борынгы кешеләрнең матурлык идеалларын, сынлы сәнгать кануннарын, яңалыкларын бирерлек бер дигән җирлек булган. Кеше, хайван, үсемлек рәсемнәре, бик нык гадиләштерелеп, савытның кырыйларына ясалган. Бу аеруча җир эшкәртүче кабиләләр мифологиясе белән бәйле. Билгеле, орнамент ул ребус түгел, бертөрле бизәк төрле кабиләләрдә төрле мәгънәдә булырга мөмкин. Әлеге рәсемнәр савыт эчендәге ризыкны саклый торган бер магик образ да. Шулай да, иҗатның башка өлкәләре кебек үк, борынгы орнаментлар да күп мәгънә аңлатканнар. Орнамент – әлегә шактый катлаулы һәм аз өйрәнелгән чыганак. Әмма аның традицион һәм ыру-кабиләгә, халыкка аерым төр бизәкләр системасы хас булу этник процессларны (миграция, ассимиляция, культуралар бәйләнешын) шактый төгәл билгеләргә ярдәм итә.

Борынгы кеше өчен рәсемнәр генә түгел, гади сүз дә табигатькә, тирә-юньгә тәэсир итәрлек кодрәтле көчкә ия булган. Мәсәлән, «Сак-Сок» турындагы хикәяттә дә әниләре сүзен тыңламаган балаларга каргыш бик тиз төшә. Әниләре каргагач, ике туган бер-берсе белән мәңге очрашмас кошларга әверелә. Шулай да сүз сәнгате башка борынгы сәнгатьләргә караганда соңрак барлыкка килә, чөнки аның өчен телнең, абстракт фикерләүнең, шартлылык аша асыл күренешне күз алдына китерә белүнең формалашуы шарт.

Борынгылыкта гомер буе акыл туплаган ата-бабалар сүзе зур хөрмәткә ия булган. Өлкәннәр сүзеннән мәкаль-әйтемнәр барлыкка килгән. Ыру учагы янында иң мөхтәрәм кешеләр – аксакаллар озын-озын хикәяләр сөйләгәннәр, табигатькә, утка, авыруларга тәэсир итәрлек сүзләр әйткәннәр. Алардан без хәзер дә яратып укый торган әкиятләр, табышмаклар барлыкка килгән. Яшь буынны мондый сүзләр белән генә түгел, йолалар, зур сынаулар белән дә тәрбияләгәннәр. Димәк, борынгыларның үз мәктәпләре булган. Дөрес, алар без белгән мәктәпләрдән бик нык аерылып торганнар: анда дәреслекләр дә, дәфтәрләр дә булмаган. Әмма мондый мәктәп-сынауны һәркем үткән. Балигъ булыр алдыннан яшь егетләрне, ыру яши торган урыннардан ерак, куркыныч урыннарга алып китеп, аучылыкка, дошманнарга каршы көрәшергә, авыр сынаулар аша сабырлыкка, түземлелеккә өйрәткәннәр. Табигатьнең тагын бик күп серләренә, ыру тәртипләренә төшендергәннәр. Шуннан соң гына аларга аучы сөңгесе бирелгән, шуннан соң гына алар ыруның тулы хокуклы кешесенә әверелгәннәр. Бу бик авыр һәм зур сынау булган. Аны үтә алмаучының хәтта яшәргә дә хокукы булмаган. Кырыс тормыш шартлары шуны таләп иткән.

Инде үзебезнең Идел-Чулман буйларына якынрак килик. Идел болгарларына кадәрге чордан калган археологик ядкәрләргә күз салыйк.

Безнең якларның борынгы заман сәнгатен өйрәнүчеләренең иң күренекле галимнәреннән берсе – Фоат Хәсән улы Вәлиев. Ул болгарларга кадәрге җирле кабиләләр сәнгате хакында да хезмәтләр язды. Аның һәм башка белгечләрнең фикерләренә өстәп, шуны әйтәсе килә: безнең якларның беренче игенчеләре, терлекчеләре, тимер коючылары булып археологиядә Казан тирәсе дип йөртелгән кабиләләр санала (я.э.к. XVI–IX гасырлар). Неолит чорында ныклап яшәеш алган орнамент бу кабиләләр сәнгатендә дә үсешен дәвам итә. Монда бизәкләр савыт-сабага тешле тарак яки үрелгән бау белән төшерелгән; төрле киңлектәге сынык һәм кыек сызык, чыршы, түгәрәк, иләк эче кебек орнаментлар күп кулланылган. Кабилә кешеләре маңгайларын кояш символын белдергән ярымшарлар белән бизәгәннәр.

Сәнгать һәм аның белән бәйләнешле карашлар аеруча Ананьино кабиләләрендә (я.э.к. VIII–III гасырлар) ачылып китә. Чыннан да, җирле сәнгать һәм карашларның үсеше әйтерсең моңа кадәр буылып торган да кинәт кенә ташкын булып ургылган. Ананьино кабиләләре сәнгатенең, дөньяга карашларының төрлелеге, катлаулылыгы шул хакта сөйли.

Аларны безнең якларда беренче тимер коючылар дидек. Шулай ук бу кабиләләрне беренче шәһәр-ныгытма төзүчеләр дип тә әйтеп була. Ананьинолылар Урал, Себер, Урта Азия, Кавказ халыклары, хәтта ерак Иран, Греция дәүләтләре белән дә сәүдә багланышларында яшәгәннәр. Алар арасында Себер, Алтай якларыннан күчеп утырган төрки кабиләләр дә булган. Ананьино кабиләләренең борынгы ырулык җәмгыяте таркалуга йөз тоткан.

Ананьино кешеләре савыт-сабада гына түгел, башка көнкүреш әйберләрендә дә матурлык күрергә омтылганнар. Җиһазларның бер төренә гадәти бизәк төшерсәләр, икенчеләрендә магик, гамәли як өстенлек иткән. Бу чорда беренче кешелек җәмгыятенә хас реализм һәм натурализм әкренләп шартлылыкка, схематик, орнаменталь сәнгатькә күчкән.

Искә төшерик әле: иң борынгы сынлы сәнгатьтә хатын-кызлар ничек сурәтләнә иде? Йөзсез, киемсез, тупас, җенси билгеләре аерылып торган сыннар итеп. Ананьино хатын-кыз сыннарында беренче тапкыр төрле матур киемнәр, бизәнү әйберләре күзгә ташлана. Алар озын җиңле күлмәк кигәннәр, алъяпкыч япканнар, билләренә бизәкле билбау бугаппар. Өс киемнәренә төрле һәм бик күп бизәнү әйберләре асканнар. Маңгайларына бизәкле тасма беркеткәннәр. Сыннарда тагын бик күп чигә алкалары, күкрәкчәләр, йөзекләр, беләзекләр күрергә була. Болар инде – Ананьино кабиләләренең хатын-кыз идеалы. Билбауга кайчак пычак яки көзге беркетелгән. Көзге матур киенгән һәм бизәнгән хатын-кызны явыз көчләрдән саклау өчен дә кирәк булган.

Ананьино кабиләләрендә дә хайван сурәтләренә киң урын бирелгән. Әмма инде бу – борынгы тотемистик карашлардан шактый ераклашкан, көчкә, кодрәткә дан җырлаган сугышчан фәндә «ерткыч стиле» дип аталган сәнгать. Мондый стиль мал асраучылык белән шөгыльләнүче скиф-сак дөньясында аеруча яратып кулланылган. Хайван сыннары белән бергә сугыш һәм эш кораллары да бизәкләп эшләнгән.

Ананьино кабиләләре диннәрендә кояшка табынганнар, уңыш китерүче хатын-кыз алласы турында төрле карашлар туган, аерым хайваннар изгеләштерелгән.

Ананьино культурасын пьяноборлар (Татарстандагы Пьяный Бор (хәзерге Красный Бор) авылы исеме белән бәйле) дәвам иттерә. Аларда да җир асты дөньясына ышану дәвам итә. Ирләр – сугыш, эш кораллары, хатын-кызлар бизәнү әйберләре белән бергә күмелгән. Пьянобор хатын-кыз киемен билгә буып куела торган эполет сыман каптырмалар, төсле тимердән ясалган өс киеме зиннәтләре, күкрәккә кадап куела торган ялтыравык түгәрәк калайлар, чигә алкалары, муенсалар бизәгән. Болардан тыш читтән – Хорезм, Иран, Византия, Түбән Идел, Төньяк Кавказдан китерелгән әйберләрне дә яратып кулланганнар.

Югары Кама төбәкләре белән бәйле Ломоватов культурасы (V–VIII гасырлар) аеруча үзенчәлекле. Бу археологик культурага караган кабиләләр хәзерге коми-пермякларның борынгы бабалары санала. Алар-

га куыш сыннар ясау, челтәрле аеллар, бизәкле билбаулар, ат сыны рәвешендәге асмалар, кыңгыраучык-төймәләр кебек бизәнү әйберләре хас. Ломоватовлылар сәнгатендә сюжетлы рәсемнәр дә күп. Алар бу кабиләләрнең дөньяга бик катлаулы карашларын чагылдыралар. Ломоватовлылар я.э.ның беренче меңьеллыгында яшәсәләр дә, алар сәнгатендә әле беренче кешелек җәмгыяте идеологиясе үзен бик сиздерә. Монда аеруча анимизм – җаннар, рухлар дине өстенлек итә. Күп кенә сыннар, рәсемнәр беренче кешелек җәмгыятенең таркалган чорына кадәрге карашлар үсешен тасвирлый. Мисалга кош сыны рәсемнәрен китерергә мөмкин. Алар бу чорда кояш, һава символларына һәм аучыларга уңыш китерүчеләргә әверелгәннәр. Ә хайван сурәтләре арасында җирле хайваннар еш очрый. Соңрак фантастик хайван сурәтләре дә барлыкка килә. Алар еш кына төрле хайванның характерлы өлешләрен бергә кушу нәтиҗәсендә тудырыла. Мәсәлән, ерткыч йөзле поши, сусар гәүдәле ат. Югарыда әйтелгәнчә, мондый сурәтләр – ыру, кабиләләрнең берләшүен, кабиләләр союзы барлыкка килүен күрсәтә торган дәлилләр.

Әлеге чорда җирле сәнгатьтә ярым кеше, ярым хайван сурәтләре дә ешая. Алар җирле мисалларда хайван алладан кеше аллага күчеш идеясен чагылдыралар. Болар да – сыйнфый җәмгыять туып, аңа хас бер, кеше аллалы диннәр туу алды күренешләре. Шул ук вакытта кояш культы нык таралыш ала. Бу күпсанлы түгәрәк бизәнү әйберләре, дүрт кош башлы боҗралар табылуда күренә.

Сәнгатьтә кеше сурәте ясауга игътибар итә башлыйлар. Монда инде кешенең үз-үзенә хөрмәте, ышанычы арту күренә. Ул шул чорга хас модалы киемнәр, бизәнү әйберләре белән сурәтләнә. Ир-ат сурәтләре дә хатын-кыз сыннарыннан калышмый. Аларда ир кеше иң беренче чиратта көчле, кодрәтле һәм кораллы итеп гәүдәләнә.

Болгарларга кадәрге Урта Идел, Кама буе сәнгате башта скиф-сармат, ә инде VI – VIII гасырларда сасанилар Иранының көчле тәэсирендә үсә.

Шулай итеп, кешелек культурасының иң озын, иң кыен, әмма иң әһәмиятле чоры артта кала. Бу чорда шул чор яшәеше, табигать белән аерылгысыз бәйләнгән бербөтен культура, сәнгать, дин барлыкка килә. Шул рәвешчә киләчәк культураларга нигез салына. Кешелек бу чорны – үзенең бала чагын бүген дә өйрәнә. Тарих чоңгылларында югалып калган кыйммәтләребезне яңадан торгызып киләчәккә бара.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

*Абрамова З.А.* Изображение человека в палеолитическом искусстве Евразии. М. ; Л. , 1966.

*Алексеев Н.А.* Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. Новосибирск : Наука, 1980.

*Анисимов А.Ф.* Духовная жизнь первобытного общества. М. ; Л. : Наука, 1966.

*Бадер О.Н.* Каповая пещера : палеолитическая живопись. Москва, 1965.

*Бакиров М.* Шигърият бишеге : гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм борынгы формалары. Казан : Мәгариф, 2001.

*Буриан Йозеф Аугуста-Зденек.* Жизнь древнего человека. Прага : Артия, 1960.

*Валеев Ф.Х.* Древнее и средневековое искусство народов Среднего Поволжья. Йошкар-Ола : Марийс. кн. изд-во, 1975.

*Генинг В.Ф.* Азелинская культура (III–V вв.) : очерки по истории Вятского края в эпоху великого переселения народов. Ижевск ; Свердловск, 1963.

*Давлетшин Г.М.* Очерки по истории предков татарского народа. Казань : Татар. кн. изд-во, 2004.

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан : Татар. кит. нәшр., 1999.

*Дәүләтшин Г.М., Хуҗин Ф.Ш., Измайлов И.Л.* Татарстан тарихыннан хикәяләр : урта мәктәпнең 5–6 с-флары өчен д-лек. Казан : Мәгариф, 1993.

*Еремеев А.Ф.* Происхождение искусства. М. , 1970.

*Золоторёв А.М.* Родовой строй и первобытная мифология. М. : Наука, 1964.

*Любимов Л.* Искусство древнего мира. М. : Просвещение, 1992.

*Мәхмудов Х.Ш.* Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкәрләрендә афоризмнар). Казан : Фикер, 2002.

*Рыбаков Б.А.* Язычество древних славян. М. : Наука, 1981.

*Столяр А.Д.* Происхождение изобразительного искусства. М. , 1986.

*Токарев С.А.* Ранние формы религии. М. : Политиздат, 1990.

*Шахнович М.И.* Первобытная мифология и философия. Л. : Наука, 1971.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш

3

Миф

7

Дин

19

Сәнгать

35

Файдаланылган әдәбият

50

Научно-популярное издание

Для детей среднего и старшего школьного возраста

***Давлетшин** Гамирзан Миргазянович*

**ДАВНЫМ-ДАВНО...**

**Миф, религия, искусство**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

Урта һәм югары сыйныфта укучы мәктәп балалары өчен

***Дәүләтшин** Гамирҗан Миргаҗан улы*

**БОРЫН-БОРЫН ЗАМАНДА...**

**Миф, дин, сәнгать**

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.12.2009. Форматы 60´90¹/₈.
Басма табагы 6,5. Тиражы 2000 д. Заказ В-1489.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.